وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!** *(Коръән, 3:103)*

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№12 (233). ДЕКАБРЬ - 2014 / САФӘР¯РАБИГЫЛӘҮВӘЛ - 1436

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ

**Газетада Аллаһы тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга куллanудан сакланыгыз!**




3 бит

"Азан" радиосына – 1 яшь!



5 бит

Олуг Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләмнен дөньяга килүе



12 бит

Садака ысулы

# МӘҮЛИД БӘЙРӘМЕ МӨБАРӘК БУЛСЫН!



**Әссәләәму галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ!**

**Мөхтәрәм дин кардәшләребез!**

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән барлык мөселманнарны Мәүлид бәйрәме белән ихластан котлыйм!

Мәүлид - сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең туган көне рабигыләүвәл аеның 12 нче кичәсенә туры килә. Мәүлид - Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең дөньяга килүенә ихлас күңелдән шатлануны белдерә торган вакыт.

Мәүлид көнен билгеләп үтү - Аллаһы рәсүле салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең тормышын өйрәнүне, аны олылауны, Коръән аятьләре, догалар, вәгазьләр укуны үз эченә ала. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам узган юлны һәм аның сөннәт гамәлләрен белү рухыбызны тәрбияләү, ныгыту булып тора.

Аллаһы Раббыбыз Коръән-Кәримдә пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам хакында болай дигән:

**"Хакыйкатьтә, син - югары әхлак иясе"** ***("Нун" сүрәсе, 4 нче аять).*** Аллаһы илчесе галәйһиссәламнең әхлак нигезе - Коръән булган. Аллаһы тәгалә Кәламе шәрифне Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә иңдереп, аны олылаган һәм боерган:

**"Ий Мөхәммәд галәйһиссәлам! Кешеләргә Аллаһының юмартлыгы вә рәхмәте илә иңдерелгән Коръән белән сөйлә һәм аларны Коръән белән гамәл кылырга өндә! Коръән иңдерелгән өчен һәм аның белән гамәл кылганнары, Аның рәхмәтләре өчен шатлансыннар!"** ***("Йунус" сүрәсе, 58 нче аять).***

Бар галәмгә Аллаһының рәхмәте булып килгән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең күркәм Мәүлид кичәсендә Коръән аятьләре укып шөкрана булыйк, дин кардәшләребез белән бергә Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә багышлап салаватлар әйтик. Бер-беребезгә, илебезгә иминлек, бәрәкәт сорап догалар кылыйк.

Барчабызга да Аллаһы Сүбхәәнәһү үә тәгаләнең рәхим-шәфкате язсын! Өммәтебезгә Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең сөннәтенә ияргән хәлдә яшәргә насыйп итсә иде! Амин.

Ихтирам белән,

***Татарстан Республикасы мөфтие***
***Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН***



13 бит

Кышкы ялларда кайсы мәхәлләләрдә балалар өчен мөселман лагерьлары ачыла

## МӨСЕЛМАННАР ӨЧЕН ИЗГЕ КӨН – МӘҮЛИД БӘЙРӘМЕ ЯКЫНЛАША

**2014 елның 23 декабрендә мөселман календаре буенча өченче айга – рәбигыләүвәл аена аяк бастык. Аны халыкта Мәүлид ае дип йөртәләр.**

Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең туган көне рәбигыләүвәл аеның 12 нче көненә туры килә. Рабигыләүвәл аенда мәчетләрдә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм турында вәгазьләр укыла, мөселманнар өйләрендә мә?лесләр үткәрәләр, мохта?ларга ярдәм итәләр, сәдакалар өләшәләр.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм туган айда Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте дә байтак чаралар үткәрергә планлаштыра. 3 гыйнварда Болгарда Мәүлид бәйрәме уздырылачак, ә 4 гыйнварда исә Теләче районында нәзарәт карамагында эшләүче ятим балалар приюты ачыла. Шулай ук мәүлид аенда коръәнхафизларыбыз Кол Шәриф мәчетендә өзлексез Коръән укый башлаячак.

## КФУДА ИСЛАМ ИКЪТИСАДЫ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШТЕЛӘР

**Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин "Бүгенге заманда Россиядә ислам икътисад-хокук модельләрен төзү һәм тормышка ашыру" дип аталган фәнни-гамәли түгәрәк өстәлдә катнашты.**

Сөйләшү КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты уздырган "Россиянең бүгенге заман ислам хокукы һәм икътисады" укулары кысаларында барды. Ул ислам икътисады-хокукы юнәлешенең таныла баруын, Россиядә бизнесны алып баруда ислам нигезләренә таяну күренеше артуын, ислам хокуклары һәм икътисады белгечләрен әзерләү мөһимлеген күздә тотып оештырылды. Сөйләшүдә Татарстан Премьер-министрының ислам финанс институтлары белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчесе Линар Якупов, Арбитраж суд рәисе Николай Новиков, Ислам үсеш банкы вәкилләре һәм башкалар катнашты.

## КАРИЛЕ АВЫЛЫ МӘДРӘСӘСЕНӘ – 300 ЕЛ

**5 гыйнварда Балтач районының Кариле авылында 300 ел элек нигез салынган авыл мәдрәсәсе тарихына багышланган авыл бәйрәме һәм имамнар җыелышы уздырыла. Мәдрәсә тарихын, мирасын өйрәнү һәм яшь буынга кайтару максатыннан оештырылган чарада район имамнары, галимнәр, мәртәбәле кунаклар катнашыр дип көтелә.**

Кариле авылы заманында имамнар әзерли торган Кариле мәдрәсәсе белән мәшһүр була. Татар дин галиме Шиһабетдин Мәрҗани мәгълүматлары буенча, унсигезенче йөзнең башларында ук Кариле авылында татар дөньясына билгеле булган шактый зур мәдрәсә эшләгән. Аның мөгаллиме Габдессәлам бине Хәсән әл-Кариле (Габдессәлам хәзрәт) була. Казан артының төрле авылларында имамлык иткән күп сандагы татар дин әһелләре шушы мәдрәсәдә Габдессәлам хәзрәттән дәрес алганнар. Мөхәммәтгали бине Зәйнелгабидин Карилedә укыган чорында үзенең атаклы "Мелла Җами" китабын яза. Ризаэддин Фәхреддиннең "Асар" хезмәтендә Кариле мәдрәсәсенә һәм анда дини гыйлем биргән мөгаллимнәргә, укыган муллаларга кагылышлы күп сандагы мәгълүматлар тупланган. Октябрь революциясеннән соңгы чорда Кариле мәдрәсәсе биналары әле озак еллар мәктәп итеп файдаланыла. Аннары алар башка авылга күчерелә.

Бүгенге көндә авылда яңа мәчет эшләп килә. Авылның яңа иман йорты 20 ел элек салынды.

## "АВЫЛЫМ МӘЧЕТЕ" ФОТОКОНКУРСЫНА ЙОМГАК ЯСАЛДЫ

**Азнакай мөхтәсибәтенең aznislam.ru сайты оештырган "Авылым мәчете" фотоконкурсына йомгак ясалды. Конкурста республиканың 9 районыннан 14 авыл мәчете катнашты. 5500 кеше онлайн тавыш бирде.**

Иң күп интернет тавышны Ютазы районы Кече Урыссу авылы мәчете фотосы җыйды, авторы - Алинә Шәрифуллина. Шулай ук фотоларны бәйсез жюри бәяләде. "Иң яхшы авыл мәчете фотосы" номинациясендә беренче урынны Арча районы Яңа Кырлай авылы мәчете фотосы (фотоны 13 яшьлек Таңсылу Сабирова төшергән) алды. Фото татар авылы рухын чагылдыргаы өчен югары бәяләнде. Заманча мәчетләр белән чагыштырганда бу иске мәчет бик җыйнык. Калкулык өстенә салынган иман йорты күп еллар дәвамында бик күркәм сакланып, авыл горурлыгы булып торуын дәвам итә. Иман йорты авыл халкының үткәне белән бүгенгесен бәйли. Шул рәвешле бу фото конкурсның төп темасын - авылым мәчете дигән сүзләрне ачып бирә.

Беренче урыннарны алучыларга 3000 сумлык бүләк сертификатлары тапшырылды, башкаларга да бүләкләр өләшенде.

## БОЛГАРДАГЫ АК МӘЧЕТ МӘДРӘСӘСЕНДӘ КОРЪӘН ӨЙРӘНҮ КУРСЛАРЫ АЧЫЛДЫ



**Камил хәзрәт Сәмигуллин Болгардагы Ак мәчет мәдрәсәсендә Коръән өйрәнү курсын ачты. Дини гыйлем бирү максатыннан оештырылган укуларны ачу тантанасында мөфти урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, район имаммөхтәсибе Фәрхәт хәзрәт Минсәгыйров һәм Кама аръягы төбәге мөхтәсибләре, район имамнары катнашты.**

Әлеге курста барлыгы 45 көн дәвамында 25 кеше Коръәнне һәм аның тәфсирләрен өйрәнәчәк. "Исламда гыйлем туплау зур дәрәҗә. Динебездә белем алуга бик зур игътибар күрсәтелә. Корънне белү исә рухыбызны тагын да ныгыта һәм Аллаһы тәгаләнең савапларына ирешергә ярдәм итә", - дип билгеләп узды мөфти Камил хәзрәт Коръән уку курсларын ачу тантанасында.

Болгарда оештырылган укулар кысаларында Болгар җирендәге тарихи һәйкәлләр, рухи мирас белән танышу да каралган. Киләчәктә мондый төр курс хатын-кызлар өчен дә оештырылыр дип көтелә.

## МӨФТИ БӨТЕНРОССИЯ ИСЛАМ ОЛИМПИАДАСЫ ҖИҢҮЧЕЛӘРЕН КОТЛАДЫ



**Россия ислам институтында ислам дәресләре һәм гарәп теле буенча җиденче тапкыр Россиякүләм олимпиада үтте. Олимпиадага йомгак ясау тантанасында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашты һәм гыйлем алу мөһимлеген аңлатып, барлык катнашучыларга зур тырышлык күрсәткәннәре өчен рәхмәт белдерде, җиңүчеләрне бүләкләде.**

Олимпиадада Татарстан, Башкортстан, Дагыстан, Чечня, Ингушетия, Кабардино-Балкария, Мордовия, Карачай-Черкес республикаларыннан, Мәскәү, Түбән Новгород, Оренбург, Саратов, Ульяновск, Самара шәһәрләре ислам уку йортлары шәкертләре катнашты. Барлыгы 20 дән артык дини уку йорты студентлары гыйлемнәрен сынады. Шунысы сөендерә, олимпиада елдан-ел үсә һәм күбрәк студентларны җәлеп итә.

Тантанада катнашкан РИИ ректоры, мөфти урынбасары Рәфыйк Мөхәммәтшин, мөфти урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, Казан шәһәре телләрне үстерү һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итү бүлеге җитәкчесе Илнур Шакиров шәкертләрне гыйлемле булырга чакырдылар. Илнур әфәнде катнашучыларга Казан мэры Илсур Метшин исеменнән бүләкләр тапшырды. ТР МДНнең "Хәләл" стандартлар комитеты белгечләре исә олимпиадада катнашучыларның барысына да Казанның 3нче ипи заводы пешергән чәк-чәкләрне күчтәнәч итеп өләште.

# "АЗАН" РАДИОСЫНА – 1 ЯШЬ!




***"Азан - ислам авазы" интернет-радиосына 1 яшь тулды. Ул - "Хузур" нәшрият йорты карамагындагы киң колач белән үсеп килүче интернет-проектларның берсе. Нәшрият йорты ачып җибәргән "Islam-today.ru" мәгълүмат-яңалыклар порталы, "Хузур-ТВ" интернет-телевидениесе бүгенге көндә инде тулы куәткә эшли.***

"Азан" - бары тик мөселман тематикасына багышланган тапшыруларны татар һәм рус телләрендә әзерләүче Татарстанның беренче ислам радиостанциясе. Ислам кыйммәтләрен күрсәтү, динебезнең тынычлык сөюче асылын киң җәмәгатьчелеккә җиткерү - радио эшчәнлегенең төп максаты әнә шулардан гыйбарәт. Активлыгын көннән-көн арттыра барып, ул атналык аудиториясен инде 5 мең кешедән арттырды. "Азан"ны көн саен дөньяның 9 илендә - Россия, Казахстан, Украина, Кыргызстан, Әзербайҗан, Төркия, АКШ, Үзбәкстан, Таҗикстан, Бөекбританиядә тыңлыйлар.

Яңа тапшырулар, кызыклы әңгәмәләр, интерактив аралашу - болар барысы да бүгенге көн таләбе. Шуны күздә тотып, "Азан" интернет-радиосы студия кунаклары, тыңлаучылар белән бергә борчыган проблемаларны уртага салып сөйләшә һәм бергәләп чишү юлларын эзли. Радиода һәр атнаның пәнҗешәмбе иртәсендә, турыдан-туры эфирга "Ислам тәгълиматлары" тапшыруы чыга. Тапшыру кунаклары - Казан шәһәре мәчетләрендә имамлык итүче укымышлы хәзрәтләр, дин белгечләре.

Хәзер "Азан" тапшыруларын радиодулкыннар аша ишетеп кенә калмыйча, телеэкраннар аша күзәтеп бару мөмкинлеге дә бар. Моның өчен бары радио сайтына (http://radioazan.ru) кереп "Сетевизор" дигән бүлеккә басу җитә. Һәм сез радио тыңлаучыдан телевизор караучыга әвереләсез!

Күптән түгел генә радионың алып баручылары хәзрәтләр белән берлектә хәләл һәм хәрам турында тапшырулар циклын ачып җибәргәннәр иде. Чираттагы яңа тапшыру шушы циклдан, гаилә коруның асылына, ир һәм хатын, аларның бер-берсенә карата хакларына багышлана. Шулай ук сүз никах, талак мәсьәләләре турында барачак. Әгәр шушы темага кагылышы сораууларыгыз бар икән, рәхим итеп студиягә шалтырата (тел.: 8(843) 2020797), язып җибәрә аласыз (radioazan@mail.ru.). "В контакте" социаль челтәрендәге төркемгә кушылып (www.vk.com/radioazan), сораулар шунда да язып калдырырга була. "Азан" интернет-радиосы сезнең фикерләрне-сорауларны көтә!

# УҢАЙ ТӘҖРИБӘНЕ УРТАКЛАШЫРГА КИРӘК

***Нәрсәләр эшләнде, ә нәрсәгә тешебез үтмәде — ел тәмамланып килгәндә һәркайсыбыз әнә шуларны барлый. Бүгенге көндә Татарстанның 45 мөхтәсибәтендә ниләр эшләнгәне дә һәрвакыт безнең күз уңында.***

Имам-мөхтәсибләр – дин өчен Аллаһ каршында, мөфтиебез каршында, хөкүмәт каршында җавап бирүчеләр. Аларның эшне ничек оештыруыннан күп нәрсә тора. Эшләрен бик оста итеп, намус белән башкара торган мөхтәсибләр, әлбәттә, күпчелекне тәшкил итә. Кайсылары әле эшкә өйрәнеп кенә килә. Мөхтәсибәт – бер мини-мөфтият ул, аның кул астында дистәләгән мәчет. Без, мөфти хәзрәтнең ярдәмчеләре булган кебек һәр мөхтәсибнең дә дүрт урынбасары булырга тиеш, дигән фикердә торабыз.

Хәзерге вакытта имамнарыбызның яртысыннан күбрәге – бабайлар. Бишүн елдан аларның мәчетләре яшьләр кулына кала. Мөхтәсибләрнең яшьләр эшләре буенча ярдәмчеләрен Диния нәзарәтенә җыйганда нәкъ менә шуны күздә тоттык. Килеп нәзарәт белән танышсыннар, төрле районнардагы коллегалары белән аралашсыннар, дидек. Мөхтәсибәттә яшьләр өчен нәрсәләр эшләнә, нинди мәшәкатьләре бар, ни җитә, ни җитми, нинди ярдәм кирәк – өчәр минут вакыт биреп, һәркайсыннан әнә шулар турында сөйләттек. Бу җыелу тәҗрибә уртаклашу, тәҗрибә туплау җәһәтеннән, миңа калса, бик тә файдалы булды. Сүз бирүчә, кайберләре эшчәнлекләре турында җәелеп китеп сөйләми, бәлки ояладыр инде, риядан булыр дип тә куркалардыр. Миңа районнарда күп йөрергә туры килә, бик күп кызыклы әйберләр күзәтәм, сораулар бирә-бирә шулар хакында аларның үзләреннән сөйләттем, уңай тәҗрибәне башкаларга да тыңлатасым килде. Мәсәлән, Сарман, Түбән Кама районнарында балалар өчен мөселман лагерьларын зур биналарда, кунып яши торган итеп оештыралар. Ашаган белми – тураган белә, дигәндәй, монда бит әле иганәчеләрен табарга, шартларын тудырырга кирәк. Яшьләребезнең бер-берсенә сөйләрлек, өйрәтерлек эшләре күп, шуңа күрә киләчәктә бу җыелышларны төрле районнарга чыгып, ай саен үткәрергә килештек.

Әлбәттә, мөхтәсибәтләрдә четерекле мәсьәләләр дә юк түгел. Мәсәлән, кайбер мөхтәсибләр барысына да үзләре йөрмәкче. Мөхтәсиб, әлбәттә, районда гы дини тормыш өчен җавап бирүче кеше. Әмма эшне яшьләргә бүлеп бирмичә, барын да үзе алып барырга маташса, мөхтәсибәтне артта калдыруы бар.

Шулай ук һәрбер мөхтәсибнең уку эшләре буенча да ярдәмчесе булырга тиеш. Күптән түгел без аларны да Диния нәзарәтенә җыйдык. Әлбәттә, дини гыйлем бирү буенча республикада шактый тәҗрибә тупланып килә, ярдәмчеләрнең һәрберсе чыгыш ясады. Мәсәлән, Арча районын алсак, алар укытуны 51(!) мәчеттә оештырганнар. Кукмаралылар әнә үзенчәлекле бер ысул уйлап тапканнар. Анда районның барлык укучысы – олысы-кечесе атнага ике көн район үзәгендәге мәдрәсәгә килеп укый.

Укыту эшләре буенча Балтач, һичшиксез, алдынгы район. Алар Коръән уку конкурсына бер яңалык керткәннәр. Бәйге берничә номинациядә бара, бер генә сүрә белгән бала да конкурста катнаша ала. Ә менә икенче елны ул инде югарырак номинациядә катнашырга тиеш. Ел дәвамында бер сүрә дә ятламагансың икән, гафу ит! 6 мең кеше яши торган Балтачта Коръән конкурсына 200 бала катнаша. Кайсы шәһәребез шундый күрсәткеч белән мактана алыр икән?

Бер урында тормыйбыз, әлхәмдулилләһи, алга барабыз. 70 ел дәвамында динсезлектә яшәгән булсак, күп нәрсәләрне кабаттан өйрәнә-өйрәнә 20 ел буе дингә кайтып барышыбыз. Без генә түгел, хөкүмәт тә дин әһелләре белән эшләргә өйрәнеп килә. Менә күптән түгел генә мәчет-мәдрәсәләрдә укыту өчен лицензия алырга диган закон кабул ителде. Хәзер шул турыда баш ватабыз, чөнки авыл мәчетләрен санитария, янгын куркынычсызлыгы таләпләренә туры китерү мөмкин түгел. Ә без укытмасак интернет, башка агымнар башкачарак укыта башларга мөмкин. Президент Аппараты, Прокуратура, Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә бу хәлдән чыгу юлын эзләп таптык шикелле. Мөхтәсибәткә бер лицензия алыначак. Ул исә һәр мәхәллә өчен җаваплылыкны үз өстенә ала.



***Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН,***
***Татарстан мөфтие урынбасары***

## Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәлләм ядкаре Мәскәүгә килә



**Мәүлид ән-Нәби уңаеннан, махсус очкыч яллап, Мәскәүгә Дагыстаннан Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәлләмнең чәчен китерәләр. Бу - мөселманнар өчен чын бәйрәм бүләге, чөнки әле моңа хәтле бу изге ядкарьне Мәскәүгә алып килгәннәре юк иде.**

# Антарктидада беренче мәртәбә намаз укылды

**"Антарктида-100" фәнни һәм мәдәни-тарихи чараларны берләштерүче проект. Әлеге экспедициядә катнашучылар боз континентында бозлы суга кереп, 97 метр тирәнлеккә төштеләр. Моңа кадәр әле берәүнең дә бу кадәр тирәнлеккә чумганы юк иде. Экспедициядә катнашучылар үзенчәлекле фәнни мәгълүматлар да җыйдылар. Аннары алар, Беллинсгаузен поляр станциясенә барып, Кол Шәриф мәчетеннән алып килгән Коръәннең "Казан басмасы"н, Казан Изге Ана иконасын, Казан синагогасыннан Тәүратны тапшырдылар. Соңыннан Антарктидада беренче мәртәбә намаз укылды.**



# СӨЕКЛЕ ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ САЛЛӘЛЛАҺУ ГАЛӘЙҺИ ҮӘ СӘЛЛӘМНЕҢ ДӨНЬЯГА КИЛҮЕ

**Кайс бин Махрамнан (Аллаһы аңардан разый булса иде) тапшырыла ки, ул әйткән: "Мин һәм Аллаһының рәсүле галәйһиссәләм Фил елында тудык" (Тирмизи). Бу хәдистә әйтелгәнчә, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәлләм Фил елында туган. Гарәпләрдә тарихи чорларны елның бөек вакыйгалары белән билгеләү гадәте булган, шундыйларның иң мәшһүре - филләр белән бәйле вакыйга. Аның кыскача тарихы түбәндәгедән гыйбарәт.**



Абиссиния (Эфиопия) Йәмән илен яулап алганнан соң, абиссин патшасы Йәмәннең хәлифәсе итеп Әбрәхә әл-Әшрама дигән кешене билгеләгән. Әбрәхә барлык абиссиннар кебек нәсари (христиан) динендә булган. Сана шәһәрендә бер зиннәтле чиркәү төзеткән һәм аны Калийс дип атаган. Ул гарәпләрне Кәгъбәтуллага түгел, ә шул чиркәүгә хаҗ кылырга мәҗбүр итәргә тырышкан. Бу эш уңышсыз булганлыктан, Әбрәхә үз максатына көч кулланып ирешергә карар кылган. Ул Кәгъбәтулланы җимереп, барлык кешеләрне үз чиркәвенә юнәлдерергә теләгән. Моның өчен зур гаскәр җыйган һәм сугыш өчен кирәк булган барлык әйберләрне әзерләгән. Әбрәхә, гарәпләрнең күңелләренә курку салыр өчен, күпсанлы филләр белән Мәккә тарафына юнәлгән. Юлда берничә киртәләр очрамагач, ул Мәккәгә Таиф шәһәре янындагы якынайган һәм үз гаскәре белән Мугаммис дигән җирдә туктаган. Шуннан соң Әбрәхә Мәккәгә юлчабарын җибәргән һәм аңа шәһәрнең аксакалын алып килергә кушкан. Юлчабар аның сүзен үтәгән һәм Корәеш кабиләсенең аксакалын - Габделмутталибны алып кайткан. Аксакал озын буйлы, зур гәүдәле һәм тәэсирле кыяфәткә ия булган.

Әбрәхә аны күреп сокланган, үз тәхетеннән торып Габделмутталиб янына килгән. Келәмгә утырып, тәрҗемәчесенә әйткән:

- Ул миннән нәрсә тели, шуны сора?

- Синең сугышчыларың минем 200 дөямне урлап киттеләр, аларны миңа кире кайтар, - дип әйткән Габделмутталиб.

Шунда Әбрәхә тәрҗемәчесенә болай дип әйтергә кушкан:

- Мин кыяфәтеңне күреп сокланган идем, ләкин сүзләреңне ишеткәч, сиңа карата фикерем үзгәрде. Мин Кәгъбәтулланы - динегезнең мөбарәк йортын җимерергә килдем, ә син 200 дөяңне сорыйсың, - дигән.

- Мин - дөяләрнең хуҗасы, ә Кәгъбәтулланың үз хуҗасы бар. Ул аны үзе саклаячак, - дип җавап биргән Габделмутталиб.

- Миннән саклый алмас, - дип әйткән Әбрәхә.

- Ничек телисең, шулай эшлә, - дигән Габделмутталиб.

Аңа дөяләрен кайтарганнар. Мәккәгә әйләнеп кайтканнан соң, Габделмутталиб барлык кешеләргә тауларга китәргә әмер биргән, үзе белән берничә кеше Кәгъбәтулла янына килгән һәм капкасының бәҗраларын тотып дога кылганнар, Аллаһыдан ярдәм сораганнар.

Әбрәхә үзенең гаскәрен һәм филләрен җыеп, Кәгъбәтулланы җимерү нияте белән, юлга чыккан. Кинәт, ниндидер сәбәп аркасында, филләр җиргә яткан һәм торырга теләмәгәннәр.

Көтмәгәндә, Аллаһының ихтыяры белән, төркем-төркем кошлар очып килгән һәм дошманнарга ташлар яргыта башлаганнар. Таш эләккән һәр сугышчы шунда ук һәлак булган. Гаскәр тулысынча тар-мар ителгән, ә Әбрәхәнең тәне тарала башлаган. Аны Сана шәһәренә алып кайтканнар, ул шунда җан биргән...

Нәкъ менә шул елны Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи үә сәлләм анасының карынында була. Әлеге вакыйга Әбрәхә гаскәренең җиңелүенә сәбәп була. Бу Пәйгамбәребезнең бөек шәхес булуына ишарәле.

Әлеге вакыйга турында Аллаһы тәгалә "Фил" сүрәсен иңдерә: "Раббыңның фил хуҗаларын нишләткәнен күрмәдеңмени? Аллаһы аларның мәкерле теләкләрен юкка чыгармадымыни? Аллаһы аларның өстенә төркем-төркем Әбабил кошларын җибәрде. Алар өстенә кызган утлы ташлар яудырды. Соңыннан Ул аларны орлыгы сугып алынган салам кебек теткәләп бетерде".

Дошман тар-мар ителгәннән соң, Аллаһының чиксез рәхмәте һәм рөхсәте белән, бөтен дөньяда изге нур балкыды. Бу нур - сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи үә сәлләмнең тууы.

Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи үә сәлләмне тапканда Әминә башка хатыннарда була торган бернинди авырлыклар сизми, ләкин ул изге төшләр күрә. Аларда хәбәр бирелә: "Дөреслектә, син үзеңдә бу өммәтнең бөек кешесен йөртәсең. Аңа Мөхәммәд дип исем бирерсең". Шундый төшләрне Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең бабасы Габделмутталиб та күрә.

Фил гаскәрен Аллаһы тәгалә һәлак иткәннән соң илле көн узгач, Әминә бөтен галәмнәргә сөенеч, шатлык, бәхет китерүче изге, нурлы бала таба. Әлеге бөек көн - рабигыләүвәл аеның 12 нче көне. Бу мөбарәк көнне кешеләр күп кенә гадәти булмаган вакыйгаларга шаһит булалар.

1. Сыннар, потлар урыннарыннан кузгала, ә кайберләре сәҗдә кыла, чөнки аларны җимерәчәк кеше дөньяга килә.



2. Мәккәдән чыккан нур Шам (Сүрия) сарайларын нурландыра, чөнки бөтен дөнья буенча иман нурын таратучы кеше туа.

3. Хишам бин Урва сүзләре буенча, бу көнне бер яһүди - Мәккә сәүдәгәре - корәешлар утырган урынга килә һәм әйтә: "Әй корәешлылар, бүген сездә бер бала тумадымы?" Алар: "Белмибез", - ди. Яһүди әйтә: "Аллаһу әкбәр! Белмәсәгез, белегез. Мин әйткән сүзләрне истә калдырыгыз. Бүген бу өммәтнең пәйгамбәре дөньяга килде. Аның ике калак сөяге арасында бер билге бар", - ди.

4. Хассан бин Сабит (Аллаһы аңардан разый булса иде) сөйләгән: "Миңа җиде-сигез яшь иде. Мин күргән һәм ишеткән нәрсәләрне аңлый идем. Бер көнне иртә белән Ясрибта (хәзерге Мәдинә шәһәре) бер яһүд кешесе кычкырып әйтте: "Әй яһүдиләр!" Аның янына кешеләр җыелды. Мин аларның сорауларын ишеттем: "Нәрсә булды сиңа, бичара?" Ул әйтте: "Дөреслектә, бүген Әхмәд (пәйгамбәребезнең икенче исеме) исемле йолдыз балкыды, ул бүген төнлә туачак".

5. Мәхзум бин Хани әл-Мәхзуми сөйләве буенча, пәгамбәребез галәйһиссәләм туган төнне фарсылар патшасы Хәсрәүнең террасасы тетрәнә, унике балконы җимерелә. Утка табынучыларның мең еллар дәвамында өзлексез янган утлары сүнә.

6. Аллаһының рәсүле Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи үә сәлләм туган елда яңгыр күп ява: игеннәр, җиләк-җимешләр башка елларга караганда күпкә уңышлырак була.

Ошбу сүзләр кемгәдер сәер булып тоелырга мөмкин, ләкин бу - хаклык. Бу вакыйгалар төрле тарихчылар тарафыннан өйрәнелгән. Алар барысы да боларның берничәсен арттырусыз булганлыгын раслый. Әлеге вакыйгалар Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи үә сәлләмнең киләчәктә бөек шәхес булачагын күрсәтә.

Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең бабасы Габделмутталиб, оныгының туусын белгәч, бик сөенә, тизрәк аны күрергә ашыга. Оныгын кулына алып үбә, шуннан соң аны саклык белән изге Кәгъбәтулла янына алып килә. Габделмутталиб Аллаһыга шөкер итә, оныгы өчен дога кыла, аннары аңа Мөхәммәд дип исем куша.

Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы тәгалә безгә иң хәерле, иң гүзәл, иң нурлы пәйгамбәр - Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи үә сәлләмнең өммәтеннән булырга насыйп итте. Раббыбыз Аллаһы бу турыда Коръән-Кәримдә болай дип әйтә: "Сез кешеләрнең иминлеге өчен дөньяда мәртәбәгә күтәрелгән иң игелекле өммәт булдыгыз. Игелеккә өндәп, яманлыктан ваз кичәргә чакырдыгыз. Аллаһыга ышанасыз" ("Гыймранның гаиләсе" сүрәсе, 110 нчы аять).

Гомәр бин Хәттаб (Аллаһы аңардан разый булса иде) әйткән: "Бу аятьтә Аллаһы тәгалә: "Сез хәерле өммәт булдыгыз", - ди. Монда сүз сахабәләр турында бара, чөнки алар чын мәгънәсендә Пәйгамбәребез галәйһиссәләм өйрәткәнчә яшәде, алар аңа ихластан иярде, аннан үрнәк алды. Безгә хәерле өммәт булыр өчен сахабәләр кебек изге гамәл-гыйбадәтләр кылып яшәргә, һәр урында һәм һәрвакытта да Аллаһыга һәм Аның рәсүле Мөхәммәд галәйһиссәләмгә итагатьле булырга, үзебезне һәм башкаларны изгелеккә өндәргә һәм явызлыктан тыярга тырышу тиешле".

Барчабызга да сөекле Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәлләмнең сөннәтләрен үтәп яшәргә насыйп булса иде!

*Нияз хәзрәт САБИРОВ,*
*ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе,*
*Апанай мәчете имам-хатыйбы*

**Газетаның узган санында без Мәүлид бәйрәме уңаеннан Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәлләмгә багышланган шигъри әсәрләргә конкурс игълан иткән идек. Редакциягә шигырьләр килү дәвам итә. Әлеге сәхифәдә шуларның берничәсен укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итәбез. Ә конкурска йомгак "Дин вә мәгыйшәт"нең гыйнвар санында ясалачак.**

## Галәм сере

Кешелекне
Бер мизанга салу өчен,
Җәннәтеңә
Кабат тартып алу өчен,
Җибәргәнсең
Галәмнәргә хәбибеңне.

Нәбиеңнең
Сөннәтенә тигезләргә,
Үлчәүләргә
Куелачак гамәл, хисем.
Бер урында
Һич таптанмас зирәк кешең.
Бу дөньяда
Ризалыгың алу өчен.

Башак булып
Сибелгәннәр җир өстенә,
Коръән нурын
Сеңдерә алган изге бәндә.
Рәхмәтеңә
Шөкер итү – галәм сере,
Яшәр дөнья,
Каплый алмас кара пәрдә!

***Сания ШӘРӘПОВА,***
***Чүпрәле***

## Сәлам сиңа, Рәсүлебез!

Болытлардан күләгәләр ясап,
Безнең бәхетебез хакына,
Аллаһының соңгы Рәсүле
Килде Җирнең барча халкына.

Сәлам булсын сиңа, Рәсүлебез,
Безне тугры юлга күндердең.
Иман нурын йөрәкләребезгә,
Бәгырьләребезгә иңдердең.

Үзең күпме михнәт кичермәдең,
Җәфа чигеп, кайгы күрмәдең,
Сүнмәс өмет белән бүләкләдең
Мөэминнәребезнең йөрәген.

Хәдисләрең безгә маяк булды
Хак юллардан дөрес барырга.
Синең үткән бөтен
тормышыңнан
Тырышабыз үрнәк алырга.

Аллаһының соңгы
тавышы булган
Коръән-Кәрим тотып колларга,
Язсын иде фани дөньяларда
Бары игелекләр кылырга.

***Мөҗәһит***
***ӘХМӘТҖАНОВ***

***

*Әссәләәмү галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ! Хөрмәтле редакция! "Дин вә мәгыйшәт" белән мин Казанның Гаилә мәчетенә укырга йөри башлагач таныштым. Газетагыз бик ошый, һәр яңа санын көтеп алам. Эчтәлекле газета чыгаруыгыз өчен Аллаһның рәхмәтләре яусын. Сәламәт булыгыз, озын гомерләр, бәрәкәтле, тыныч тормышлар телим. Ихтирам белән, Яшел Үзән районы Бишнә авылыннан*

***Сөмбелә АБДУЛЛИНА***

## Пәйгамбәребезгә мәдхия...

Коръән өйрәткәнчә яши
Ислам динен үз итүче,
Мөэмин-мөселман булганның
Олысы һәм кечесе.

Пәйгамбәрдән үрнәк ала.
Ул - күркәм, бөек, изге...
Мөхәммәд Пәйгамбәребез –
Аллаһының Илчесе.

Раббыбыздан иңгәннәрне
Җиткерә белгән безгә...
Оста булган, батыр булган,
Тора белгән сүзендә...

Сабыр булган сокланырлык,
Җиңгән күп авырлыкны...
Үз артыннан иярткә алган
Җирдә күпме халыкны.
Алга сөргән изгелекне,
Тугрылыкны, хаклыкны...

Тыйнак булган, яхшылыкны
Эшләгән адым саен...
Сокланып аның турында
Укыймын тагын-тагын...

Шәригать кануннарын ул,
Үтәргә кушкан безгә...
Рәхмәт укып, баш иямен
һәрчак Рәсүлебезгә.
Пәйгамбәр кушканны үтәү
Язсын һәрберебезгә...

***

## Җәннәтләрдә булсын өммәтең

Бөтен җиһан сине көтеп алды,
Төштә күрде анаң Әминә.
Синең туу - дөнья өчен рәхмәт,
Урын алдың безнең күңелдә.

Бер Аллаһның Илчесе син,
Пәйгамбәребез Мөхәммәд
Саллаллаһу галәйһиссәлләм,
Кешелеккә булдың үрнәк!

Тормышыңның тәүге көне
Узды Саад кавеме янында.
Кире каккач, сөт анасы сине,
Күкләр ярсып, яңгыр яумады.

Корылыктан җирләр кипте,
Сусызлыктан ар(ы)ды кешеләр.
Тик бер болыт йөри
баш өстеңдә –
Сине саклаганны күрмиләр..

һәм Хәлимә – сөт анаң үзеңне
Назлы итеп алды кочакка.
Көйдерүче кояш нурларыннан,
Сыендырды гүя ышыкка.

Бер Аллаһның илчесе син,
Пәйгамбәребез Мөхәммәд
Саллаллаһу галәйһиссәлләм,
Кешелеккә булдың үрнәк!

..Нурлы Мәдинәгә юл алдың
Ум Айман һәм анаң бергәләп.
Алты яшьтә ятим булуыңны
Сиздең баккач, атаң каберенә.

Әл-Абвада вафат әниең дә,
Ялгызлыкны сиздең бик яшьли.
Ярый әле бабаң, абыеңның
Мәхәббәте булды бик көчле.

Мәккә балалары дәшкән чакта,
Әниләрен һәрчак ярдәмгә.
Күз яшеңне күрсәтмәскә теләп,
Карап тора идең син җиргә.

Бер Аллаһның илчесе син,
Пәйгамбәребез Мөхәммәд
Саллаллаһу галәйһиссәлләм,
Кешелеккә булдың үрнәк!

... Әр-Нур тавы, Хира мәгарәсе.
Берьялгызың. Иңде Фәрештә.
Син – Аллаһның
соңгы пәйгамбәре,
Вәхи килде сиңа кырык яшьтә.

Изге Коръән сүзе ирешкәндә
Караңгылык җирдән югалды.
Әйтерсең лә бар җан ияләре
Көтеп алган яңа көн туды.

Бер Аллаһның Илчесе син,
Пәйгамбәребез Мөхәммәд
Саллаллаһу галәйһиссәлләм,
Кешелеккә булдың үрнәк!

Әй, өммәтем, әй, өммәтем диеп,
Тәнең-җаның белән борчылдың.
Без инандык синең Илчелеккә,
Бер Аллаһны танып буйсындык.

Безнең өчен син кырыкта
сыман.
Һич төшмисең безнең
телләрдән.
Әй, Мөхәммәд
(Аллаһ риза булсын!)
Салават әйтәбез бергәләп.

Әй, Мөхәммәд,
өммәтем дип, безгә
Ислам динен, юлны күрсәттең.
Синең казаныш ул – иман белән
Җәннәтләрдә булса өммәтең!

***Нурфия ХАЛИКОВА***

## Мәүлид бәйрәме

Рабигыләүвәл аеның
Унберенче көнендә
Сөекле пәйгамбәр туа,
Ислам нуры җәелә.
Тәрҗемә итсәң гарәпчәдән
Мәүлид – ул "туу" була,
Мөхәммәд галәйһиссәлләм
Дөньяга аваз сала.

Аңа пәйгамбәрлек бирә
Аллаһы тәгаләбез,
Шуңа аның туган көнен
Зурлап бәйрәм итәбез.
Мәңгелек бәхет, рәхәттә,
Яшәргә сәгадәттә
Шушы фани дөньябызда,
Шулай ук ахирәттә
Хак тәгаләнең илчесе
Тугры юлны күрсәтә,
Шәфәгатен өмет итеп
Халык салават әйтә.

## Иң ахыргы пәйгамбәр

Иләһи рәхмәт йөзеннән,
тугры юлда йөрсенгә,
Хаклык белән хаксызлыкны күрә,
тоя белсенгә

Аллаһы тәгалә безгә –
адәм балаларына
Пәйгамбәрләр, рәсүлләрен
гел-гел җибәреп торган.

Габдуллаһ углы Мөхәммәд –
ахыргысы аларның,
Корәеш кабиләсеннән,
ул гарәп кавеменнән.

Аннан соң булмас бер рәсүл,
булмас һичбер пәйгамбәр,
Шуңа аны ахырзаман
пәйгамбәре дигәннәр.

Аллаһ тәгаләдән башка
булалмый һичбер иләһ!
"Лә-иләһә-илләл-лаһү
Мухәммәдүр рәсүлуллаһ."

***Асия КОРБАНГАЛИЕВА,***
***Әгерҗе***

***

Пәйгамбәребез – Мөхәммәд,
Китабым – изге Коръән.
Әбиемнең догаларын
Һәрчак күңелдә йөртәм.
Башларыма кайгы килсә
Дога кылам Раббыма.
Әй, Аллаһым, сабырлык бир,
Рәхмәтеңнән ташлама.
Коръән белән гамәл кылып,
Аллаһ кушканча яшик.
Пәйгамбәребез сөннәтен
Барчабыз дәвам итик.

***Ләйсән СӘГЪДИЕВА***
***Кама-Тамагы районы,***
***Балчыклы авылы***

*Әссәләәмү галәйкүм, хөрмәтле "Дин вә Мәгыйшәт " газетасы хезмәткәрләре! Мәүлид бәйрәменә багышланган конкурс турында укып белгәч, сезнең тарафка үзебезнең мәхәлләдән шигырь юлларга булдык. Авылыбызның шагыйрәсе* **Рәмзия ҖИҺАНГӘРӘЕВА** *дини темага шактый шигырьләр яза. Аның әсәрләрен мәчеттә узучы дини мәҗлесләрдә дә укыйбыз. Әнисе белән бергә, бик күркәм итеп, халкыбызда сакланып калган мөнәҗәтләрне дә башкаралар алар.*

*Сезгә ихтирам һәм хөрмәт белән Әгерҗе районы имам-мөхтәсибе, Кичкетаң авылы имам-хатыйбы хаҗи Мөхәммәтазат хәзрәт Гатин.*



## Олуг Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи үә сәлләм

Олуг Пәйгамбәребез Мөхәммәд,
Аллаһының син хак хәбибе.
Җир йөзенә дин-ислам тараттың,
Җиһанга Коръәни-Кәрим иңде.

И Мөхәммәд, Аллаһ илчесе син!
Күп милләтләр сиңа килделәр:
"Ислам дине - бөек бер мәгълүмат,
Ихлас ышанабыз", - диделәр.

Динең дөрес, юлың дөрес булган,
Илләр, халык сиңа тартыла.
Коръән сүрәләрен, аятьләрен
Бар кешеләр укып таң кала.

Галимнәрнең олы ачышлары
Күп гасырлар элек язылган.
Коръән кануннарны да
сыйдырган,
Кешелеккә тугры юл сызган.

Гасырларны гасыр алыштырды,
Сокландырып синең хезмәткә,
Кешелекнең Бөеге дип тану,
Олы зурлау синең хөрмәткә.

Хәдисләрең мөселманнар өчен
Олы сабак, дәрес билгесе.
Синең әдәп, әхлак, тормыш юлың,
Рухи камиллекнең өлгесе.

Синең варисыңнан бер сахабә
Килеп Бөек Болгар иленә
Татар халкын –
безнең бабайларны
Инандырган ислам диненә.
Сахабәнең каберен
күреп кайттым,
Ул бүген дә затлы урында.
Болгар шәһәренең күрке булып
Гүя сөйли синең турыда.

# ФӘНИС ХАҖИӘКБӘР ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ САЛЛӘЛЛАҺУ ГАЛӘЙҺИ ҮӘ СӘЛЛӘМНЕ ТӨШЕНДӘ КҮРДЕ

**Ярдәм мәчетендә үзе кебек үк күрмәүчеләргә компьютер гыйлемен өйрәтүче мөгаллим Фәнис Мингәрәев быел изге җирләргә барып, хаҗ кылып кайту бәхетенә иреште. 1988 елда Казанда Рәис һәм Гүзәл Мингәрәевләр гаиләсендә дөньяга килгән Фәнискә яшьтән үк дини гыйлем алу насыйп була. Ул мәктәптән соң Казан Ислам көллиятендә белем ала, аннары "Мөхәммәдия" югары мөселман мәдрәсәсен тәмамлый. Хәзерге вакытта Фәнис Рәис улы Казандагы Россия Ислам институтының бишенче курсында укый. Хаҗ сәфәреннән кайткач, миңа аның белән әңгәмә кору насыйп булды.**

***- Фәнис хәзрәт, сөйләшүне хаҗга юллама алуыгыздан ук башлыйк әле.***

- Аллаһы тәгаләнең рәхмәте дип аңлыйм мин аны. Рамазан аендагы язмышлар билгеләнә торган Кадер кичәсендә мин елый-елый дога кылдым. "Раббым, якын араларда хаҗ нигъмәтләрен тоя алсам иде. Сөекле рәсүлебез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи үә сәлләм йөргән сукмаклардан, юллардан йөрер, сәҗдәләр кылыр идем", - дип Хак тәгаләдән гозерләнеп сорадым. Үзем дә сизмәстән, төне буе елап чыктым. Шуннан соң, ике көн вакыт үтте микән - анысын хәтерләмим, Казан мэры Илсур Метшин безнең Ярдәм мәчетенә килеп, бик зур ифтар мәҗлесе үткәрде. Мин вәгазь сөйләдем, Коръән укып, дога кылдым. Аннары үземә күрсәтелгән урынга, ягъни Илсур Рәис улы янына килеп утырдым. Шунда ул: "Фәнис", - дип миңа мөрәҗәгать итте. Аның мәҗлес турында минем фикеремне беләсе киләдер дип уйлап: "Илсур Рәисович, шундый матур ифтар мәҗлесе үткәргәнегез өчен Сезгә Аллаһының рәхмәте яусын", - дидем. Ул: "Яхшы сүзләрегез өчен рәхмәт, тик мин башка нәрсә турында әйтмәкче идем. Сине шатландырасым килә. Мин Илдар хәзрәттән бер изге теләгең барлыгын белдем, аны үтәргә алынам. Сине һәм сине озатып йөрүче бер ир кешене быел хаҗ сәфәренә җибәрәм", - диде. Мондый сүзләрдән мин аптырадым да калдым. Авызымны ни ачарга, ни ябарга белмим. Күзләрем ачылып китеп, нинди куаныч кичерер булсам, ул мизгелләрдә мин шундый ук сөенечле халәт кичердем. Һич арттырып әйтмим! Шулкадәрле шатландым, аны сөйләр өчен сүзләр генә җитәрлек түгел.

Шуннан соң мин хаҗга әзерләнә башладым. Мине үзебезнең Ярдәм мәчете хезмәткәре Альберт Федоров озатып йөрде, дөресрәге, ул мине кулымнан җитәкләп йөртте.

***- Юлларыгыз бик авыр булмадымы соң?***

- Юк, зарланырлык булмады. Бер төркем булып җыелып, 23 сентябрьдә Казаннан Төркиягә очтык. Анда безне кунакханәгә урнаштырдылар. Бер тәүлектән соң Согуд Гарәбстанына юл алдык. Ихрамны кигәч, Мөхәррәм исемле төрек кешесе татар телендә шулкадәрле көчле вәгазь сөйләде! "Сезнең исемегез ничек?"- дип сорады ул бездән. Без фәлән улы фәлән дип, чын исемнәребезне әйтә башладык. Шунда ул: "Хәзер бу исемнәрне онытыгыз, сезнең исемегез Хаҗи", - диде. "Фамилиягез ничек?"-дип сорады ул кабаттан. Бу юлы инде без телебезне тешләдек, чөнки аның хикмәт белән сөйләвен аңлаган идек инде. Мөхәррәм кардәшебез үз соравына үзе үк җавап та бирде. "Сезнең фамилиягез хәзер - Сабыр", - диде ул. "Сез Мәккәгә эксперт сыйфатында барасызмы? Юк, сез - Аллаһы тәгаләнең кунагы. Сез Мәккәгә теләсә-нәрсә тикшереп йөрергә килмәдегез. Кирәкмәгәнне күрмәгез, Хак тәгаләнең нигъмәтен тоеп, ләззәтләнеп гыйбадәт кылып кайтыгыз", - диде ул. Шул сүзләр юлыбыз буена үзе бер гыйбрәтле үгет-нәсыйхәт булды. Нинди генә авырлык килеп чыкса да үз-үземнән: "Син кем исемле?" - дип сорый идем. Аннары: "Хаҗи исемле!"- дип үзем үк горурланып җавап та бирәм. "Фамилияң кем?" "Сабыр". "Мәккәгә эксперт рәвешендә бармыйбыз", - дия идем. Бу сүзләр һәрчак көч, сабырлык биреп торды.

Төркиядә госелләнеп, ихрам киеменә төренгәч, өскә шулкадәрле зур җаваплылык япты! Ихрамым буялмаса гына ярар иде, дип бер борчылдым. Ике тукыма кисәгеннән генә торса да, ул бит гади кием түгел. Аннары Хак тәгаләгә гыйбадәт кылу башланды, дигән шатлыклы җаваплылык та бар бит әле. Кыскасы, җилкәгә Өхед тавы төшкән сыман булды.

Микат чиген очкычта узганлыктан, ихрамны Төркиядә үк кияләр икән. Очкычта хаҗ кылу ниятен башкардык һәм Согуд Гарәбстанының Җиддә дигән каласына килеп төштек. 25 сентябрь иртәсендә автобуста Мәккәгә чыгып киттек. Юлда таһарәт алып, намазлар укыдык. Берзаман безне таныш булмаган кешеләр туктаттылар да: "Аллаһының ризалыгы өчен булсын", - дип күчтәнәчкә ризыклар биреп киттеләр. Зәм-зәм суларын да бушлай тараттылар. Аллаһының рәхмәтләре яусын ул кешеләргә! Мәккәгә барып җиткәч, кунакханәгә урнаштырдылар. Әз генә хәл-әхвәл алгач, ахшам белән ястү намазларын укыдык. Тукланып алгач, Әл-Хәрам мәчетенә юнәлдек. Җитәкчебез безгә Кәгъбәтуллага барып җиткәч кенә күтәрелеп карарга киңәш бирде, ягъни биредә тыйнаклык күрсәтү кирәк икән. "Корольләр кебек кыланмагыз, Аллаһы тәгаләгә мохтаҗ икәнлегегезне күрсәтеп барыгыз, чөнки Раббыбыз тыйнак кешеләрне сөя", - диде ул. Мин Кәгъбәтуллага барганда юл буе Аллаһы тәгаләдән хәерле хаҗ кылуны сорадым. Аннары мине озатып йөрүче Альберт хаҗиның: "Фәнис, килеп җиттек!" - диюе булды, күзләремнән мөлдерәп яшь агарга тотынды. Үксеп елавымны туктата гына алмыйм. Фикерләрем дә каядыр юкка чыкты, елыйм да елыйм. Бу хәл тәүге тапкыр гомрә хаҗын кылырга баргач булды. Без башта, хаҗыбызны Раббыбыз кабул итсен, дип дога кылдык. Аннары тавaф кылырга, ягъни Кәгъбәтулла тирәли әйләнергә керештек. Аны 7 тапкыр әйләнеп чыккач, тагын дога кылдык. Мин вакытның үткәнен дә сизмәдем, ару-талуны да белмәдем. Кеше күп иде, билгеле. Авыр дисәң, авырга кала. Мин, әйтерсең, фәрештәләр канатына утырып очтым. Тавaф кылгач, догалар кылы-кыла зәм-зәм сулары эчтек. Ике ракәгать намаз укыдык. Аннары сәгъи кылдык. Бу гамәл Әл-Хәрам мәчете белән бер түбә астында булган Сафа һәм Мәрвә тауларын 7 мәртәбә йөреп чыгудан гыйбарәт. Ике урында йөгереп үттек. Әл-Хәрам мәчетендә эшебез беткәч, бераз чәчләребезне кыскарттык, аннары кунакханәбезгә кайтып, ихрамнан чыктык. Ә инде олы хаҗ вакыты килеп җиткәч, без тагын госелләнеп, ихрам кидек. Аннары безне Мина үзәнлегенә алып киттеләр.

***- Мина үзәнлегендә адашып йөрүчеләр булмадымы?***

- Юк, андый хәлләр булмады. Без чатырларда яшәдек. Анда бар да - дустың да, бер белмәгән кардәшең дә Аллаһыга гыйбадәттә. Бөтен эшләрен ташлап, туган якларын калдырып, шуның өчен бирегә җыелганнар бит инде. Шуларны





уйлый-уйлый, үзебезгә һәм туганнарга Аллаһыдан саулык-сәламәтлек сорап, дога кылдык. Аннары безне Гарәфәт тавына алып киттеләр. Әлхәмдүлилләһ, Гарәфә көне изге җомгага туры килде. Безнең өчен бу икеләтә бәйрәм булды. Аны "хаҗиәкбәр", ягъни " бөек хаҗ" дип атыйлар икән. Хаҗ кылу көне җомгага туры килсә, берничә хаҗга тиңләшә, диләр. Бу вакыйга 12 елга бер тапкыр гына килә икән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм дә җомга көнне хаҗ кылган. Шуңа күрә аның белән хаҗ кылган савабы языла, диләр.

Гарәфәт тавы итәгендә өйлә һәм икенде намазларын укыдык. Мин Әр-Рәхмәт тавына менмәдем, ләкин аның итәгендә бик озаклап дога кылып, Коръән укып утырдым. Анда да бертуктаусыз елыйсың, туктап булмый. Шул вакытта тәнеңнән пычракны кырып төшергәндәй хис итәсең. Үзеңне сабый бала халәтенә кайтып баргандай тоясың. Кояш баеганнан соң, Мөздәлифәгә алып киттеләр. Анда да исең-акылың китәрлек. Кешеләр сөйләгәнне тыңладым: бөтен җирдә ап-актан киенгән кешеләр ята, җир өстен ап-ак кар каплаган кебек булган, ди. Башка вакыт булса, мин монда ятмыйм, дип бәлки, җылырак, уңайлырак урын эзләр идең. Ә анда, кечкенә генә кулъяулык кадәр ара тапсам ярар иде, дип йөрисең. Урыны пычрактыр, дип тә тормыйсың. Анда барыбыз да бертигез. Бер урын табып, шунда яткач, тагын фикерли башладым. Кара әле, ахирәт сәгатенең репетициясе, бер билгесе бит инде бу, дим. Әле ярый, монда ятып торырга урын бар. Алай гына да түгел, уңга да, сулга да борыла аласың. Ә Кыямәт көнендә ничәмә еллар буена үз тормышыңа бәяне көтеп басып торачаксың. Гөнаһларың өчен борчыла-борчыла, үз тиреңә үзең батып... Менә шуларны уйлый-уйлый, тетрәнә-тетрәнә догалар кылып, бер-ике сәгать йоклап үткәрдек.

Иртәнге намазны укыгач, борчак кадәрле ташлар җыйдык. Аларны кемдер сумкасына салды, кемдер пакетларга тутырды. Аннары без Мөздәлифәдән Мина тавы итәгенә кире әйләнеп кайттык. Анда берәр сәгать хәл алгач, җәмәгать белән җамаратка таш атарга юнәлдек. Дөресен генә әйткәндә, мин анда нинди хисләр кичергәнемне аңлата алмыйм. Бөтен халык таш ата. Ул тавыштан гүелдәгән аваз чыгарып, баганалар чыңлап тора. Матур итеп ләббәйкәләр, тәкбирләр әйтеп, барып җиттек таш ату урынына. Тәсбих әйткәндә үземдә әллә нинди сихри көч сиздем. Ә менә хаҗ кылып кайтканнан соң тагы да көчле булырга, дөрес булмаган гамәлләреңне гел төзәтеп, нәфесеңә даими рәвештә таш атып яшәргә тиеш буласың, дигән фикерләр белән борчак хәтле ташларны мин олы, уртанчы һәм кече баганаларга аттым. Анда да йөрәк гел тетрәнеп торды.

Аннары чатырларга кайттык. Корбаныгыз чалынды, дигән хәбәр булгач, берберебезгә ярдәм итешеп, чәчләребезне бөтенләй кыркып алдык. Ихрамнан чыгып, үз киемемне кигәндә аның нинди рәхәт, уңайлы булуы турында уйладым. Тәнгә ятып торган кием дә бит безгә Аллаһының бер нигъмәте. Шайтанга таш атарга тагын өч көн йөрдек. Аннары Мәккәдәге кунакханәбезгә кайткач, Әл-Хәрам мәчетенә барып, саубуллашу тавафын кылып килдек. Күңелне, быел бирегә башка килә алмыйбыз бит инде, дигән тойгылар биләде, бик тә моңсу булып китте.

Икенче көнне иртәнге якта без Мәдинәгә юл тоттык. Кунакханәбез Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм мәчете янында гына булып чыкты, намаз укырга гел мәчеткә йөрдек. Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең, хәлифәләр Әбү Бәкер, Гомәрнең каберләрен зиярәт кылдык, башка сахабәләрнең каберләре янында булдык. Мәчетнең бер өлешендә җир өстендәге җәннәт бакчасы бар икән. Шунда керү бәхетенә ирештек. Анда яшел төстәге keләмнәр җәелгән, диделәр. Биредә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм басып намаз укыган, вәгазь сөйләгән михраб һәм мөнбәр бар. Михрабын да, мөнбәрен дә кулларым белән капшап карадым, анда озаклап намаз укыдым. Тагын шушы михраб астында Кәүсәр чишмәсенең башланып киткән урыны бар, диделәр. Менә шул изге урыннарда булып, намаз укыдым. Биредә син һәм Аллаһы тәгалә генә бар, арада башка беркем юк - менә шуны сизәсең анда. Аннары Өхед тавына менеп, дога кылдык. Элек Әл-Әкса мәчетенә карап намаз укый торган гыйбадәтханәдә, Әл-Куба дигән мәчеттә булдык. Әл-Куба - беренче намаз укыган урын. Шунда бер намаз укысаң, гомрә хаҗы кылган савабын аласың, диделәр.



***- Фәнис хәзрәт, син изге урыннарда хикмәтле төшләр күргәнсең, дип ишеткән идем. Шул хакмы?***

- Мәдинәдән китәр вакыт җиткәндә, мин Хак тәгаләдән: "Раббым, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләмне төшләремдә күрсәм иде", - дип сорадым һәм догалар кылдым. Мәдинәдән соң, без туган якларга юл алдык. Башта килгән юл буйлап Төркиягә кайттык. Анда безне кунакханәгә урнаштырдылар. Шунда миңа төш керде. Каядыр бер биек урынга - ачык һәм ап-ак һавага күтәрелгәнмен икән. Ә янымда бер якты йөзле кеше басып тора. Ул: "Фәнис, мә ал бу түбәтәйне", - дип аны үз башыннан салып, миңа бирә. Мин: "Юк, рәхмәт. Ничек алыйм, бу бит Сезнең түбәтәегез", - дим. Ул кеше: "Мин аны ихлас күңелдән сиңа бирәм, рәхәтен күреп, киеп йөр", - диде. Алдыммы мин аның түбәтәен, юкмы - хәтерләмим. Миңа калса, алдым шикелле. Ә артымнан бер тавыш яңгырады: "Ничек алмыйсың инде син ул түбәтәйне? Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи үә сәлләм аны сиңа үзе бирә бит".

Ә өйгә кайткач, тагын бер төш керде. Мин бер караңгы бүлмәдә басып торам икән. Уң якта шундый көчле яктылык, ачыклык бар. Аның нурлы җир икәнен шәйләдем. Шунда кулыма ихрам тоттырдылар. "Хәзер хаҗ кыла башлыйбыз, ихрамны киегез", - дигән аваз ишетелде. Үзем каушыйм, нишләргә дә белмим, бик борчылдым инде. Шул чагында янымнан зәңгәр чапан кигән озын буйлы бер кеше елмаеп узды. Икенче берәү яныма килде дә: "Син аша-эч, ял ит. Ике көннән хаҗ гамәлләрен башлап җибәрербез. Әле генә синең яныңнан узып киткән кеше - Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи үә сәлләм җитәкчең булыр. Аның белән хаҗ кылырсың", - диде. Менә шундый төшләр күрдем...

Без 20 көн хаҗ сәфәрендә булып, Төркия аша исән-имин генә Казаныбызга кайтып җиттек. Кылган хаҗларыбыз кабуллардан булса иде, Аллаһы тәгалә хаҗ өчен гөнаһларның ярлыкануын вәгъдә итә. Ләкин чистарындым да шуның белән эш бетте түгел. Әле алда Раббыбыз әманәт итеп биргән тормышны дәвам итәсе бар.

***- Кайбер кешеләр, хаҗга яшьтән барырга кирәк түгел, олыгайгач, гөнаһлар кылмый башлагач бару мәслихәт, диләр...***

- Хаҗга иртәрәк барган саен хәерлерәк, дип уйлыйм. Җитди сәбәпләр аркасында бара алмадың икән, анысы да Аллаһы тәгаләнең хикмәте. Күп мисаллар ишеткәнем бар. Акча да җыйган идек, тик нишләптер хаҗга барып булмады, диләр. Әгәр әлегә хәтле бара алмагансыз икән, моңа үкенеп, күз яшьләре түгәргә кирәкми. Димәк, Раббыбыз әле вакытын китереп җиткермәгән. Менә минем үземә Аллаһы тәгалә һич көтмәгәндә хаҗ сәфәрен кылырга насыйп итте.

***- Гарәбстанда ул вакытта шактый эссе булгандыр?***

- Эсселеген дә Мөхәррәм хәзрәтнең үгет-нәсыйхәте белән җиңдек. Бик авыр чакларымда аның: "Исемем - Хаҗи, фамилиям - Сабыр, мин эксперт түгел", - дигән сүзләрен искә төшердем. Шайтан безне уфтандырырга ярата. Мина тавына баргач та уфтанырга була, чөнки кеше күп, ыгы-зыгы хәттин ашкан. Авыр мизгелләре юк түгел. Әйтик, госелләнергә керәсең икән, алдыңда - 20 кеше, артыңда тагын шуның кадәр мөселман басып тора. Озатып йөрүчемә яхшылап тотынып йөрергә туры килде, чөнки азга гына кулыңны ычкындырсаң да югалуың бар. Телне белүебез дә юк дәрәҗәсендә бит. Боларның бөтенесен уйласаң, уфтанып утырырга кала. Әмма хаҗиның фамилиясе - Сабыр, ә хаҗның авырлыгы киләсе тормышыбызны җиңеләйтер, иншә Алла.

Казан мэры Илсур Рәис улына Аллаһының олы рәхмәтләре булсын. Кылган изгелекләре артыгы белән үзенә әйләнеп кайтсын иде. Гаиләсенә, хәләл җефетенә, балаларына аның һәр уңышы бәрәкәт, олуглык, нигъмәт булып ирешсен. Һәм үзенә безне күп еллар буена куандырып яшәү насыйп булсын. Мине шәһәр мэры белән таныштырып, хаҗ кылуыма сәбәпче булган Татарстан мөфтие урынбасары, Ярдәм мәчете имам-хатыйбы Илдар хәзрәт Баязитовка да Аллаһының рәхмәтләре яуса иде.

*Әңгәмәдәш –*
*Хатыйп ГӘРӘЙ*

## Шушы салаватларны укыган мөселман төшендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләмне күрергә мөмкин

**Аллаһүммә салли галә рухи саййидинә Мүхәммәдин фи-л-әрвах, үә-салли галә җәсади саййидинә Мүхәммәдин фи-л-әҗсад үә-салли галә кабри саййидинә Мүхәммәдин фи-л-кубур үә-галә алиһи үә-сахбихи үә-сәллим.**

Йә Аллаһ! Башка җаннар арасында рухи җитәкчебез Мөхәммәднең җанына рәхмәтеңне иңдерсәң иде, башка тәннәр арасында рухи җитәкчебез Мөхәммәднең тәненә рәхмәтеңне иңдерсәң иде, башка каберләр арасында рухи җитәкчебез Мөхәммәднең, аның гаилә әгъзалары һәм сахабәләре каберләренә рәхмәтеңне иңдерсәң иде.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм бу салават сыйфатлары турында болай дигән: "Миңа багышлап көн саен 3 тапкыр салават укыган кешегә мин Аллаһы тәгалә каршында шаһит булачакмын, иншә Аллаһ".

Ә Ибне Раваха болай дигән: "Көн саен 70 тапкыр бу салаватны укырга гадәтләнгән кешегә Аллаһы тәгалә Илчесе төшендә киләчәк".

**Аллаһүммә раббә-л-ашхури-л-хәрами үә-л-мәшгари-л-хәрами үә-л-бәйти-л-хәрами үә-р-рукни үә-л-макани үә-раббил-хилли үә-л-хәрами икра Мүхәммәдән минни-с-сәләм.**

Йә Аллаһ! И ашхур әл-хәрам (хәрам айларының)[1], Мәшгар әл-хәрам (Мөздәлифәдәге мәчетнең)[2] Хуҗасы! Галәм терәге Бәйт әл-хәрам[3], хәләл һәм хәрам Хуҗасы, минем сәламемне Мөхәммәдкә тапшыр.

**Аллаһүммә салли галә саййидинә Мүхәммәдин фи-л-әввәлина үә-л-ахырина үә-фи-л-мала и-л-галә илә йәүми-д-дин.**

И Аллаһ! Беренче көннәрдән соңгы көннәргә кадәр һәм фәрештәләр арасындагы Бөек Җыелышта, Кыямәт Көненә кадәр Мөхәммәдкә рәхмәтеңне иңдерсәң иде!

**Аллаһүммә салли галә Мүхәммәдив-үә-галә али Мүхәммәдив-үә-хдини мин гиндикә үә-афды галәййә мин фадликә үә-ншур галәййә мир-рахмәтикә үә әнзил галәййә бәракәтик.**

И Аллаһ! Мөхәммәдкә һәм аның гаилә әгъзаларына рәхмәтеңне иңдерсәң иде. Мине Синңа илтүче туры юлга бастырсаң иде. Миңа бәрәкәтеңне насыйп итсәң иде. Мине рәхмәтең һәм шәфәгатең белән бүләкләсәң иде.

**Аллаһүммә салли афдала салаватикә галә әсгади махлукатикә сәййидинә үә мәүләнә Мүхәммәдин нәбиййил-умми, үә галә алихи үә-сахбихи үә-сәллим адада мәглуматика үә-мидада кәлимәтикә куллиха ма закарака-з-закирун үә-гафала ан зикрика-л-гафилун.**

Йә Аллаһ! Яралткан җаннарыңның иң яхшысына, рухи җитәкчебез һәм яклаучыбыз булган, яза белмәгән Пәйгамбәребез Мөхәммәдкә, аның гаиләсе әгъзаларына һәм сахабәләренә Үзеңә генә билгеле булган микъдарда, Син иңдергән сүзләр санынча, Сине истә тотучыларның Сине искә алган вакыты һәм Сине онытучыларның Сиңа битараф булган вакытлары кадәр рәхмәтеңне иңдерсәң иде.

**Мәвләйә салли үә-сәллим дә имән әбәдән галә хәбибикә хайри-л-халкы куллихим.**

Йә, Раббым! Яралтканнарың арасыннан иң яхшысына, Үзеңнең яраткан җаныңа һәрвакыт, өзлексез фатихаңны һәм сәламеңне иңдерсәң иде.

**[1] Хәрам айлары - сугыш, золымлык тыелган дүрт ай (Зөлкагъдә, Зөлхиҗҗә, Мөхәррәм, Рәҗәб). Бу айлар турында Коръәндә "Тәүбә" сүрәсенең 36нчы аятендә әйтелгән.**
**[2] Мөздәлифә үзәнлегендә булганда Пәйгамбәребез галәйһиссәләм басып торган урында төзелгән мәчет.**
**[3] Бәйт әл-хәрам (Изге йорт) - Кәгъбәтулланың икенче исеме. Бу исем "Маидә" сүрәсенең 97нче аятендә искә алына.**

# Казанда II Республика "Хәләл" продукция ярминкәсе үтте

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы Хәләл" стандарт комитеты ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, "Казан" Агросәнәгать паркы һәм "Хәләл" милли индустрия ассоциациясе белән берлектә Казанда II Республика "Хәләл" ярминкәсен оештырды.**




Ярминкәнең эшчәнлеге "Хәләл" стандарт комитеты рәисе урынбасары Ирек хәзрәт Җиһаншинның Коръән аятьләрен укуы белән башланып китте. Аның тантаналы ачылышында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Нәҗип Хаҗипов, "Хәләл" стандарт комитеты рәисе  Марат Низамов һәм "Казан" Агросәнәгать паркының бүлек җитәкчесе Рифат Насыйбуллин катнашты.

Нәҗип Хаҗипов үзенең чыгышында "Хәләл" ярминкә оештыруны күркәм традициягә әверелдерү кирәклеге турында әйтте. Бу өлкәдә "Хәләл" стандарт комитетының әһәмиятле роль уйнавын ассызыклады.

"Хәләл" стандарт комитеты рәисе Марат Низамов үз чиратында гади кулланучылар фикеренә һәрвакыт колак салулары һәм бу ярминкәне оештырганда да аларның теләкләренә таянып эшләүләре турында сөйләде.

"Хәләл" продукция ярминкәсендә бу юлы 60 ка якын җитештерүченең хәләл продукциясе: ит һәм сөт, кондитер һәм башка төр продуктлары сатылды. Болардан тыш ярминкәдә каюлы читек, беләзек-йөзек кебек татар халкының милли байлыгын, төрле кул эшләре һәм сувенир продукция дә сатып алырга мөмкин иде. Диния нәзарәтенең "Зәкят" хәйрия фонды да актив катнашты: алар ярминкәдә балаларның кул эшләрен тәкъдим итте.

Сатып алучылар җитештерүчеләрнең хәләл продукцияләрен дегустацияләүдә дә катнашты. Соңыннан зур кызыксыну белән дөрес туклануга бәйле файдалы лекцияләр тыңладылар һәм "Мин хәләл турында нәрсә беләм?" дип исемләнгән мини-викторина сорауларына җавап эзләделәр. Чара нәтиҗәләр ясау һәм ярминкәдә катнашкан җитештерүчеләрне бүләкләү белән тәмамланды.

Шунысын да әйтергә кирәк, ярминкәгә мөселманнар белән бергә мөселман булмаганнар да күп килгән иде. Башкала халкы хәзер хәләл азык-төлекнең өстенлекләрен аңлый башлады. Хәләл продукциягә ихтыяҗның көннән-көн арта баруы шул хакта сөйли.




















# "Халык кайда – хәзрәт шунда булырга тиеш"



**"Туган авылым" ресторан-нар комплексы биләмә-сендә мәчет ачыла, дигән хәбәргә күпләр ышанырга да, ышанмаска да белмә-де. Тыелганы, хәрамы ка-тышкан күңел ачу урынын-дамы? Җитмәсә икътисади яктан да комплексның хәлләре мактанырлык түгел, соңгы елларда ул тәмам бөлгенлеккә төшкән иде.**

Комплексның яңа хуҗалары (берничә ресторан, кафелар чел-тәрен үз эченә алган Bulatov Group җитәкчеләре) - мөселман-татар егетләре булып чыкты һәм алар үз алларына комплексны хәләл сәүдә-хезмәт күрсәтү юлы белән, иман нуры иңдереп аякка бастыруны максат итеп куйган-нар. Ниятләрен Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинга да җиткергәннәр. Мөфти хәзрәт, ху-җалар белән очрашып сөйләш-кәч, барып мәчеткә тәгаенләнгән йортны караган да үзенең фати-хасын биргән. Шулай итеп, ок-тябрьнең соңгы җомгасында "Ту-ган авылым"да җомга намазы укылды.

Дөрес, мәчетнең манарасы күкләргә ашып, ерактан ук күре-неп тормый, аны мин комплекс биләмәсенә кергәч кенә шәйләп алдым. Җыйнак кына агач йорт-ның болдырына күтәрелеп, кул-тыксасына таянгач, күңелемнән бер уй үтте: "Менә Аллаһының рәхмәте! Бу баскычтан кемнәр нинди ниятләр белән күтәрелм-әгәндер. Ә хәзер намаз укырга, вәгазь тыңларга киләбез".

Түбә астында урнашкан ха-тын-кызлар залында өйлә намазы укыганнан соң, Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИНны күреп сөй-ләшергә дип ирләр залына төштем.

- Хуҗаларның биредә мәчет ачу нияте аңлашыла, чөнки бу тирәдә - үзәктә мәчетләр юк, ә килгән кунаклар арасында мөсел-маннар да шактый. Икенчедән, шундый биләмәләре була торып, әлбәттә инде, мөселман егетлә-ренең мөмкинлекне кулдан ыч-кындырасылары килмәгәндер. Аларның берсе миңа чыгып: "Әйдә, кил, йортларны карыйк әле, кайсыннан мәчет ясап булыр икән?" - диде. Кыйбланы карап, уңайлылык ягыннан чыгып, без менә шушы йортны сайлап ал-дык. Элек ул кунак йорты булып хезмәт иткән. Аста бар, бильярд, өске катта йокы бүлмәсе булган. Монда төрле гөнаһлы гамәлләр дә кылынгандыр, бәлки. Чистар-тып, келәмнәр җәйгәч, мәчет төсе керде, алай да әле ике атна-лап авыр аура бар иде. Намазлар укыгач, җомгалар үткәргәч, Алла кушып, җиңеләеп китте тагы. Җомга көнне дәресләр дә алып барабыз.



Монда мәхәллә юк, бәлки барысы да белеп бетермидер әле. Бу тирәдә эшләүче мөселман егетләре бик тиз таптылар үзе, кереп намаз укып чыгып китәләр.

- Хәзрәт, шәһәр үзәге өчен бу мәчет бәләкәйрәк, минемчә. Вәгазь тыңларга килүчеләрнең яртысы урамда басып калмыймы?

- Әйе, мәчет зур түгел, өч залга 120 ләп кеше сыя. Кеше күп йөри башласа, хуҗаларның киләчәктә бу мәчетне зурайтыр-га дигән ниятләре дә бар. Йортың кечкенә булса да, күңелең иркен булсын, диләр бит. Беркемнең дә урамда басып калганы юк, кысы-ла-кысыла булса да керәләр. Әле менә мөселман яшьләре җыелы-шы да биредә үтте. Лекция тың-лап, чәй эчеп утырдык. Андый оч-рашулар дәвамлы булса, без бер дә каршы түгел.

Бер танышым миңа: "Халык кайда - хәзрәт шунда булырга тиеш. Аның максаты мәчет кара-выллап утыру түгел, ә кешеләр белән эшләү", - дигән иде. Шул сүзләрне ишеткәч, минем күзләр ачылып китте. Бирегә шундый ният белән килдем дә. Мәчете җылымы, салкынмы, зурмы, кеч-кенәме - анысы мөһим түгел, ха-лык кына йөрсен.

***Мәрьямбану ХАФИЗ***

# АЛЛАҺЫНЫҢ ВӘГЪДӘСЕ ХАК



**Рәхимле һәм Рәхмәтле Аллаһ исеме белән. Галәмнәрнең Раббысы Аллаһы тәгаләгә мактауларыбыз булса иде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләмгә сәламнәребез барып ирешсә иде.**

**"Ий, кешеләр, Аллаһының вәгъдәсе хак, дөнья сезне алдап, ахирәт бәхетеннән мәхрүм итмәсен, һәм гөнаһ эшләсәгез дә, Аллаһ ярлыкар дип, шайтан алдамасын"** ***(Мәләйкә (Фәрештәләр)" сүрәсе, 5 нче аять).***

Аллаһы тәгалә Илчесе салләллаһу галәйһи үә сәлләм болай дигән: **"Белем алуның өч юлы бар:**

**1.Күз белән күреп белү, бу кешене ялгыш юлдан җибәрергә мөмкин.**

**2.Акыл белән аңлап белү, бу күзләрдән көчлерәк.**

**3.Акыл белән төшенеп булмаган, пәйгамбәрләр аша иңдерелгән Аллаһы тәгалә күрсәтмәләре. Бу бик акыллы кешеләрне дә таң калдыра".**

Хөрмәтле һәм кадерле дин кардәшләрем! Бүген көч һәм кодрәт кем кулында? Чын хуҗа кем? Кем үз теләге белән кешеләргә көч һәм куәт бирә? Кем үз теләге белән кемнедер көчле, ә кемнедер көчсез итә? Барлык гүзәл сыйфатларның иясе - Бер тиңдәше булмаган Аллаһы тәгалә.

Уйларыбыз белән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм шәһәренә - Мәдинәгә, иң көчле идарәче, бөек остаз, хөрмәтле тәрбиячебез янына күчик. Шәһәрдә яшәүчеләргә аның беренче сүзләре нинди булган?

Ул алар белән берничә сәгать буе сөйләшмәгән, бары тик берничә сүз генә әйткән. Ләкин бу сүзләрне игътибарлырак тыңласак, аларның халыклар белән идарә итә алырлык конституция булуын күрербез.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм Мәдинәгә килгәч, сахабәләре, кулларына корал алып, аның янына килеп басалар. Моның сәбәбе Мәдинәдә яшәүче яһүдиләрнең ышанычлы булмауларында - алар кинәт һөҗүм итәргә мөмкин.

Кешеләр Аллаһы тәгалә Илчесе салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең сүзләрен ишетергә дип җыелалар. Аның сүзләрендә беркемгә бернинди янау юк. Аның сүзләре бик йомшак, күңелләргә үтеп керерлек: **"И, кешеләр! Сәлам таратыгыз!.. Кешеләрне ашатыгыз. Туганнарыгызның хәлләрен белешеп торыгыз - хаҗәтләрен үтәгез, җәннәткә керер өчен, төнлә кешеләр йоклаганда намаз кылыгыз"**.

Бары тик дүрт җөмлә, ләкин һәрберсен алып, тозлы диңгезгә салсаң, су төчегә әйләнәчәк.

**"И, кешеләр! Сәлам таратыгыз!.."** "Сәлам" сүзе Аллаһы тәгалә исемнәренең берсе. Бер мөселманның икенчесенә сәлам бирүендә никадәр савап барлыгын беләсезме? Нәкъ утыз савап. **"Әссәләәму галәйкүм"** сәламе өчен ун савап, **"үә рахмәтүллаһи"** сүзләре өчен - ун савап. **"Үә бәракәәтүһү"** сүзләре өчен - ун савап.

Мөселман кардәшен мөселманча сәламләп шатландырган кеше, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм сөннәтен үтәгән булып исәпләнә. Чөнки бер хәдистә болай диелгән: **"Фетнә заманнарында минем сөннәтемне үтәгән кешене йөз шәһит савабы көтә".** Икенче хәдистә болай диелә: **"Сәлам таратыгыз! Аллаһыга иман китермичә җәннәткә кермәячәксез, бер-берегезне Аллаһы ризалыгы өчен сөймичә янәдән иман әһелләреннән булмаячаксыз. Сезгә ничек бер-берегезне сөяргә тиеш икәнегезне хәбәр итикме? Арагызда сәлам таратыгыз!"**

... Бервакыт Гомәр (радияллаһу ганһү) Аллаһы тәгалә Илчесе салләллаһу галәйһи үә сәлләмгә Галинең (радияллаһу ганһү) аны беренче булып сәламләмәвеннән зарланып килә. Аллаһы тәгалә Илчесе салләллаһу галәйһи үә сәлләм Галине (радияллаһу ганһү) чакырып, аннан сорый: "И, Гали, ни сәбәпле син Гомәрне беренче булып сәламләмисең?"

Бу сорауга җавап биргәнче сезне Гали (радияллаһу ганһү) белән таныштырасым килә. Сез аның нинди кеше булуын беләсезме? Бу җаны һәм тәне белән көчле кеше. Сөйләгәндә ачык һәм анык сөйли, кешеләр арасындагы бәхәсләрне җиңел чишә, хөкем чыгарганда гадел була. Ул белем чыганагы булып тора. Фани дөньяны яратмый, мал артыннан кумый, аның бердәнбер дусты - төн вакыты. Бик зирәк кеше була ул. Дусларының берсе сөйли: "Ул безнең арабыздан һәм бездән аерылып тормый иде. Сорауларыбызга һәрвакыт җавап бирә, үтенечләребезне кире какмый иде. Һәрвакыт безнең белән булуына карамастан, бөеклеге аркасында без аңа мөрәҗәгать итәргә кыймый, беренче булып сүз башлый алмый идек. Ул диндар кешеләрне хөрмәтли, фәкыйрьләрне ярата иде. Көчле кеше ялгышырга кыймый, ә көчсез кеше аның гаделлегенә өметләнә иде".

Төн җиткәч, ул михрабта утыра, сакалын тотып, ятим бала сыман сагышка бирелеп елый: "И, дөнья! Миннән башка кешене алда. Син мине ятатасың мәллә, үзеңне тәкъдим итәсең, әллә син миңа гашыйкмы? Ләкин мин сине өч талак биреп аердым. Мин сине кире кайтара алмыйм. Синең тормышың кыска, синең кыйммәтең юк, дип уйлыйм. Юкка минем игътибарымны җәлеп итәргә тырышасың. Ризык аз, юл озын һәм куркыныч.

Шуңа күрә миннән кит, башкаларны алда. Син мине алдый алмаячаксың".

"Ни сәбәпле?"

"Ни сәбәпле икәнен беләсегез киләме? Чөнки сине җирләр алдыннан юар өчен табутка салачаклар, яныңа бер фәрештә килеп сораячак: "Колакларың кайда? Сине кем саңгырау иткән? Күзләрең кайда? Нигә күрмисең? Телең кайда? Нигә сөйләшмисең? Матур тавышың кайда? Сине кем телсез иткән?"

"Сине алып киткәч, гаиләңә нәрсә әйтәчәгеңне беләсеңме? Син болай диячәксең: "И, балаларым! И, безнең киемне киючеләр, безнең йортта, безнең илдә яшәүчеләр, безнең милекне уртаклашучылар! Сак булыгыз, дөнья сезнең белән дә безнең белән уйнаган кебек уйнамасын. Мин хәрамнан хәләлне аермыйча акча тупладым. Бу акча хәзер сезнеке, аны сез кулланасыз. Ә аның өчен мин генә җавап тотачакмын... Милек - сезнеке, ә җавап - безнеке. Без җавап тотачакбыз".

Сине кабергә төшергәч, берүзең калачаксың, яныңа фәрештә килер дә болай дияр: "И, Адәм баласы! Син фани дөнья әйберләрен җыйдың, алар синең беләнме? Син дөньянымы, әллә ул сине кире кактымы? Үлемгә әзерләндеңме, әллә ул яныңа кинәт килдеме?"

"И, Адәм баласы! Синең җирдән чыгарылуың, балчыктан ясалуың хакыйкать, инде син җиргә кире кайттың. Син җирдән чиста һәм гөнаһсыз килеш чыгарылдың, ә хәзер гөнаһлар җыеп кайттың".

Сине кабергә урнаштыргач, бөтен кеше китәчәк, төн караңгысы төшкәч, сиңа Кодрәт иясе мөрәҗәгать итәчәк: "И, Адәм баласы! Алар сине монда калдырып киттеләр. Алар монда калган очракта да син алардан бернинди файда күрмәячәк идең. Синең белән Мин калдым. Мин беркайчан да үлмәячәкмен. Миннән башка илаһи зат юк. Мин чын Көч һәм Кодрәт иясе!"

Бер шәрык акыл иясе бик матур фикер әйткән: "Бу дөнья өчен мәңгелек һәм тотрыклылык юк. Без йортлар төзибез, ә алар барысы да юкка чыгачак".

Шулай булгач, бу нинди каршы тору, нинди бәрелеш соң? Нигә туганлык җепләрен өзәбез? Нигә әти-әнигә буйсынмыйбыз? Алдашу һәм мутлык, дөнья артыннан куу нигә кирәк?

Без арыбыз да кеше таптап йөри торган җирнең бер өлеше булачакбыз.

Әйдәгез, әти-әниләргә буйсыныйк, туганнарның һәм дусларның хәлләрен белешик. Хатыннарыбызга һәм балаларыбызга яхшы мөнәсәбәттә булыйк. Аларга карата игелекле һәм йомшак булыйк. Без барыбыз да балчыктан ясалган, җиргә кире кайтачакбыз да.

Гадел хакимнәр кайда? Умаййя (Омеййада) уллары кайда? Аббасидлар кайда? Госманлылар кайда? Мәмлүкләр кайда? Аллаһы тәгалә Илчесе салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең алтын чоры кайда? Аларның һәрберсе үз дәверендә яшәп, тормыштан киткәннәр. Аларның һәрберсе Кыямәт көнендә кылган гамәлләре белән генә калачак. Кыямәт көнендә зур суд булачак. Анда кем хөкем чыгарачак соң? Әлбәттә, Аллаһы тәгалә.

Аллаһы тәгалә "Фатихә" сүрәсендә бу турыда безне искәртә: **"Аллаһы тәгалә гаделлек белән хөкем итүче, Кыямәт көненең патшасыдыр"** ***("Фатихә" сүрәсе, 4 нче аять).***

И, кеше! Син: **"Я, Раббым! Безгә бу хәбәрне кем алып килде", - дип сорасаң, моңа җавап шундый булыр: "Ий, кешеләр, тәхкыйк сезгә үз арагыздан пәйгамбәр килде, Аллаһыга карышуыгыз аңар авырдыр, сезнең иманга килүегез өчен бик тырышучы, мөэминнәргә шәфкатьледер"** ***("Тәүбә" сүрәсе, 128 нче аять).***

Син Аллаһы тәгаләдән шаһитлар алып килү өчен вакыт бирүен сорасаң, бу аять белән очрашачаксың: **"Кыямәт көнендә ул пакь хатыннарны сүгүче кешеләрнең телләре вә куллары һәм аяклары кылган эшләре белән шәһадәт бирерләр"** ***("Нур" сүрәсе, 24 нче аять).***

Әгәр дә син Аллаһы тәгаләдән яклаучыны табар өчен вакыт сорасаң, түбәндәге аять белән очрашачаксың: **"Гамәлләрең язылган китабыңны укыгыл! Менә бүген үз-үзеңне хисап итәргә шул гамәл дәфтәрең җитәдер. "Гамәл дәфтәреңә карагач, үзеңне танырсың һәм кая барачагыңны да белерсең"** ***("Бәни Исраил" сүрәсе, 14 нче аять).***

Әгәр дә син: **"Я, Аллаһ! Минем судым яңадан башлансын", - дип сорасаң, түбәндәге аять белән очрашачаксың: "Минем алдымда сүзем һич алышынмас, дәхи Мин колларыма золым итүче түгелмен"** ***("Каф" сүрәсе, 29 нчы аять).***

Әгәр дә син: "И, Аллаһ! Минем милкем һәм җанымны залогка алмассыңмы?"- дип сорасаң, синең бу соравыңа җавап бу аять булачак: **"Кешеләр кубарылган көндә мине хур кылма". Ул көндә малы вә баласы һичкемгә файда бирмәс. Мәгәр мөшриклек вә монафикълык кирләреннән күңеле пакь хәлдә чын мөселман булып килсә, аңа файда булыр"** ***("Шүгәраү" сүрәсе, 87-89 нчы аятьләр)."***

Бу аңлатулардан соң Галинең (радияллаһу ганһү) Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм биргән сорауга җавабын китерик: "И, Аллаһы тәгалә Илчесе! Мин синең болай дип әйтүеңне ишеттем: "Мөселман кардәшен беренче булып сәламләгән кешегә Аллаһы тәгалә җәннәттә зиннәтле сарай төзиячәк". Шул сарай Гомәргә эләксен өчен, беренче булып сәламләү мөмкинлеген мин Гомәргә бирәм".

Аллаһы тәгалә хакына ярату, Аллаһы тәгалә хакына сабыр итү, Аллаһы тәгаләгә рәхмәтле булу, Аллаһы тәгаләдән курку, Аллаһы тәгаләгә өмет итү дип атарга була моны. Бу матур сүзләр әнә шул кешеләр турында әйтелә. Аллаһы тәгалә безне дә алар кебек итсен иде. Безне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм юлыннан алып барсын иде, безгә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм сөннәте буенча яшәү мөмкинлеге бирсен һәм җиңеләйтсен иде. Әмин.

*Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН*

## Аллаһ рәсүле салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең соңгы өч киңәше

Могтәбәр Үмм Сәләмә (Аллаһы аңардан разый булса иде) болай дигән: “Миһербанлы Аллаһ рәсүле (салләллаһу галәйһи үә сәлләм) үлем түшәгендә ятканда, теле көрмәкләнеп, тавышы гырылдап чыга башлагач, үзенең соңгы өч киңәшен әйтте: “Намаз, намаз һәм тагын бер тапкыр намаз. Сездән бәйле булганнарның хокукларын кысмагыз, хатыннарыгызга карата булган мөнәсәбәтләрегездә Аллаһыдан куркыгыз, алар сезнең белән булганда (ниндидер бер юл белән) үзләренең ирекләрен югалткан. Сез аларны Аллаһ белән килешү буенча алып, үзегез өчен хәләл иткәнсез (аларга тиешле мөнәсәбәттә булыгыз, Аллаһыдан куркыгыз)” (Ибне Мәҗә).

*Islam-today*

# НАМАЗЛАРНЫ ВАКЫТЫНДА УКУНЫҢ ӘҖЕРЛӘРЕ

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең хәдис-шәрифләрендә килгәнчә, ул (салләллаһу галәйһи үә сәлләм) намазларны үз вакытында үтәү турында болай дип әйткән: “Кем дә кем намазларын үз вакытында үтәү белән саклый икән, Аллаһы тәгалә аны мондый нигъмәтләр белән хөрмәтләр:

- тормыш авырлыгын китәрер;
- кабер газабыннан саклар;
- Кыямәт көнендә гамәл дәфтәрен уң ягыннан бирер;
- сират күпере аша яшен яшьнәгән тизлектә чыгарыр;
- җәннәткә хисап тотмыйча керер.

### Әгәр намаз укуга исе китмәсә...

Аллаһы тәгалә аны бернинчә төрле нәрсә белән җәзалар: аларның бишесе дөньяда булыр, өчесе – җан биргәндә, өчесе кабердә көтеп торыр, калган өчесе кабердән кабат терелеп чыкканда.

**Дөньялыктагылары:** гомере бәрәкәтсез булу, икенчесе – йөзеннән изгеләр нуры алыныр, өченчесе – кылган гамәлләренә Аллаһы тәгалә әҗер бирмәс, дүртенчесе – догасы күккә күтәрелмәс, бишенчесе – изгеләр догасына кермәс, керсә дә өлешсез калыр.

**Җан биргәндәгесе:** ямьсез килеш үләр, икенчесе – ач үләр, өченчесе – дөньяның бөтен диңгезләрен эчеп бетерсә дә, туймыйча сусап үләр.

**Кабергә кергәч күрә торганнары:** кабер аңа шулкадәр тар булыр, хәтта бер кабыргасы икенчесенә керер, кабере ут базына әйләнер, көнен-төнен күмер өстендә яткан булыр, өченчесе – каберендә үзен “Әш-Шуҗәгъ әл-Әкрагъ” исемле елан чорнап алыр. Ул еланның күзләре уттан булыр, тәңкәләре тимердән булыр. Һәрбер тәңкәсенең озынлыгы бер көнлек юл озынлыгыдыр. Бу елан мәет белән сөйләшер һәм аңа болай дияр: “Миңа Раббым сине намазларыңны зая кылганга күрә кыйнарга кушты, иртәнге намазыңны кояш чыгып беткәч укуыңа кыйнаячакмын, өйлә намазыңны икендегә кадәр калдырганга кыйнаячакмын, икендеңне ахшамга кадәр калдырганга кыйнаячакмын, ахшам намазын ястү вакытына кадәр калдырганга кыйнаячакмын, ястү намазын иртәнге намаз вакытына кадәр калдырганга кыйнаячакмын”.

Елан мәеткә суккан саен ул җиргә утыз култык тирәнлегенә батар. Бу кеше Кыямәт көне җиткәнче каберендә шулай газап чигәр...”

*Фәрид хәзрәт Сәлмән календареннан (2014) алынды*

## Теш сызлаганда укыла торган дога

Сахабәләрдән Абдуллаһ бине Рәвәхә (р.г.) беркөнне Аллаһ рәсүле салләллаһу галәйһи үә сәлләмгә теше сызлаудан изалануы хакында сөйләгән иде. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи үә сәлләм бәрәкәтле кулын хәзрәти Абдуллаһның авырткан яңагына куеп, болай диде: “**Аллаһүммәәзһиб гәнһү сүүә мә йәҗидү үә фәхшәһү би дагьүәтии нәбийикәль-мәкииниль-мүбәәраки гиңдәк** (Аллаһым! Синең каршыңда мөбарәк һәм мөхтәрәм булган пәйгамбәреңнең догасы белән бу тешнең авыруын ал)”. (Мевахибуль-Ләдүнния: 75).

*“Авыр вакытларда укыла торган догалар” китабыннан*

# Кыямәт көненә ышану

**Аллаһы тәгалә барлыкка китергән бу дөнья мәңгелек түгел. Вакыты җиткәч, фани дөнья бетәчәк. Ләкин үлемнән соң һәр кешене мәңгелек тормыш көтә. Кешенең бакый дөньядагы тормышы аның фани дөньядагы гамәлләренә бәйле. Барлык кешеләр дә Аллаһы тәгалә хөкеме алдында бу дөньядагы эш-гамәлләре өчен җавап тотарга тиеш. Шуңа күрә һәркемгә Кыямәт көненә алдан әзерләнергә кирәк.**

Кыямәт көненә ышану – ул үлемнән соң терелүгә, эш-гамәлләренең өчен җавап тотуга, яхшы һәм яман эшләрнең махсус үлчәүдә үлчәнүенә, сират күперенә, үлемнән соң иманлы кешеләрнең савапларга ирешүләренә һәм имансызларның мәңгелек газапларга дучар ителүенә, мөселманнар өчен сусауларын мәңгелеккә баса торган чишмәләр булуга, пәйгамбәрләрнең, фәрештәләрнең һәм бөек мөселманнарның яклавына (Аллаһы кушуы белән) инану.

Иманлы кеше Кыямәт көнендә һәркемнең үзенә тиешле җәза яки савап алуына ышана. Бу дөньядагы гөнаһлары һәм ямaнлыклары, гаделсезлекләре өчен үлгәнче җавап тотмаган кеше, теге дөньяда һичшиксез җәзаланачак. Үз гомерендә бик күп изгелекләр кылып та фани дөньяда савапларга ирешмәгән булса, үлгәннән соң тиешен алачак.

Кыямәт көненә ышану мөселман өчен бик мөһим. Чөнки кешедә үз эш-гамәлләре өчен җаваплылык хисе уяна, ул вакытын бушка әрәм итми башлый. Мөселман үзенең ап-ачык һәм яшерен гөнаһлары өчен, шулай ук Аллаһы тәгалә аңа насыйп иткән игелекләрдән ничек файдалануы турында җавап тотачак. Моны аңлаган кеше тыелганнан тыелырга өйрәнә һәм үзенең әхлагын камилләштерә.

*“Ислам турында сөйләшик” энциклопедиясеннән*

### Бөек тупланыш

Хәзрәти Гайшәдән (р.г.) риваять ителгән: "Инсаннар ул көнне элек яратылгандай, шәрә килеш хәшер ителерләр. Мин дә: "Йә, рәсүлуллаһ алар бер-берсенә начарлык эшләмәсләрме?" - дидем. Моның өстенә рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи үә сәлләм: "Аларның авырлыктан бер-берсенә карарлык хәлләре юктыр", - диде.

Алар бары тик үз хисаплары хакында гына уйлаячак, йөрәкләрен курку алачак. Ул көнне барлык кешеләр өч төркемгә бүленер. Бер өлеше бик тиз чапкан атлардай киләчәкләр. Болары - мөэминнрдер. Башкалары бераз акрын, җәяү йөреп килерләр. Болар дөньяда вакытта яхшы гамәл аз кылганнар, ваемсызлык күрсәткәннәр. Кайбер кешеләр исә йөзтүбән капланган килеш өстерәлеп килерләр. Бу ишеләренең урыны җәһәннәм булачактыр...



## Үлем – дөньядан кире кайтыш чарасы

Юлчыларыбыз калачак җирләр, кунакханәләрдә аларга тәкъдим ителәчәк шартлар аларның бу дөньяда вакытта кылган гамәлләренә күрә билгеләнер.

Өстә бүлмәләр булган, астан елгалар аккан җәннәтләрдә алар өчен матур торак җирләре хәзерләнгән.

Тәме һич тә үзгәрмәс һәм бозылмас сулары, җәннәтнең шәраблары, саф баллар ага торган җәннәтнең елгалары.

Эченә тәмле исле зәгъфран тутырылган якут, энҗе, мәрҗәннән эшләнгән түшәкләр.

Үзләре теләгән җимешләр, җаннары теләгән кош итләре.

Ә андагы киемнәр, барысы да иң яхшы тукымалардан тегелгәннәр, көмеш һәм энҗе белән бизәлгәннәр. Бик тә күркәм булыр алар һәм һәрвакыт кулланылышка әзерләр.

Бу шартларга ирешергә теләүчеләр астарак күрсәтелгән тәгълиматларны сүзгә-сүз, бик җентекләп башкарырга һәм аларга бирелгән бланк кәгазьләрен тәгәл итеп тутырып, бу эш белән шөгыльләнүче фәрештәләргә тапшырырга тиешләр. Мондагы “паспорт контролендә” түбәндәге сораулар күз алдында тотылачак:

1. Раббысының яхшы колы идеме ул?
2. Үзенең кылган гамәлләрен яхшы хәтерлиме?
3. Үзен күрмәгән килеш тә Раббысыннан тиешле дәрәҗәдә курка идеме? Аңа хөрмәт белән карады һәм буйсындымы?
4. Бирегә Кальби-Сәлим (керсез күңеле) белән килдеме?

Бу паспортта язылган күрсәтмәләрнең бермә-бер үтәлүе соралыр.

*“Мәңгелеккә юл тотучының ахирәт паспорты” китабыннан*

*Хатларыгызны Диния нәзарәтенә (Лобачевский ур., 6 нчы йорт) яисә naubahar67@list.ru адресы буенча җибәрә аласыз*

# САДАКА ЫСУЛЫ

*Үзен этник мөселман дип санаган, әмма намазын укып, уразасын тотып шәригать кушканча яшәргә омтылган милләттәшләренә нәфрәт белән карарга гадәтләнгән татарларыбыз еш кына күтәрә торган бер проблема бар: ул –садака мәсьәләсе. Намаз укымасак та, ураза тотмасак та, безнең күңелебез чиста, шунлыктан без дога кылып утыручылардан бик күпкә өстенбез дип югары үзбәя куярга гадәтләнгән әлеге кавемдәшләр бу мәсьәлә буенча еш кына матбугатта да шаушу кубарып алырга яраталар. Болар арасында да ара-тирә мәчетләргә садака керткәләүчеләр бар, чөнки күңел тыныч түгел. Үз-үзеңә никадәр генә югары бәя куйма, Аллаһы тәгалә каршына барасы бар, һәм үзбәяңнең шунда раслануына гарантияләр ай-һай юк шул.*

*Ярый хуш, садака бирелде, ди. Моның артыннан шаулап йөрүнең, акчамны зурлап кабул итмәделәр дип гауга кубаруның, хәтта ки бу хакта инде республикакүләм матбугатта да олы итеп язып чыгуның мәгънәсе нидә? Бу нәрсәне аңлата? Бердән, садаканың ихлас бирелмәвен, икенчедән XXI гасыр кешеләренең байтагы бу өлкәдә надан булуын, өченчедән, милләттә садака ысулының бозылган булуын сөйли әлеге факт. Садака бирүнең һәм алуның кагыйдәләре шәригатьтә төгәл эшләнгән һәм аңлаешлы гади булса да, кызганычка каршы, күпчелек бу хакта берни дә белми диярлек. Исламда мөселманнар өчен мәҗбүри рәвештә бирергә тиеш булган фарыз садакалар (зәкят, гошер, фитыр) булган кебек, ихтыяри, ягъни үз теләгең белән бирелә торган садакалар да бар. Бу язмада без соңгысы хакында гына сөйләшербез, чөнки шәригатьнең намаз, ураза кебек фарызларын үтәмәүчеләр, гадәттә фарыз садакаларны да биреп мәшәкатьләнмиләр. Бары тик рамазан аенда бирелә торган фитырны гына түләүчеләрне очратырга була алар арасында һәм нәкъ менә шул фитырны проблема итеп күтәрәләр дә соңыннан. Шуңа күрә фитыр турында аерым әйтеп китик. Бу садака үзенә рамазан Гаетенә бәйрәм ризыгы әзерләрлек тә хәле булмаган фәкыйрьләргә ризык белән бирелә. Бу инде билгеле бер күләмдә җимеш булырга мөмкин, башка төрле азыктан да була ала. Әбү Хәнифә мәзһәбендә ризык урынына аның бәясе күләмендә акчасын бирергә дә рөхсәт ителә. Монда тавышлана торган берни дә юк. Бер мескенгә бер утырып ашарлык (елга бер тапкыр!) татлы ризык илткәнсең икән, оятың булса, моны сөйләнеп йөрмисең инде. Сөйләнеп йөрүчеләр, гадәттә фитыр түләүчеләрдән түгел һәм аларның максаты – мөселманнарга яла ягу.*

*Риясыз бирелгән садаканың исә кеше тормышында әһәмияте бик зур. Американың Психологик Ассоциациясе дәвамлы өйрәнүләрдән соң менә мондый нәтиҗәләр игълан итте: башкаларга ихлас булышучылар үзләренә ниндидер файда өмет итеп булышучыларга яисә бөтенләй булышырга яратмаучыларга караганда күпкә озаграк яши икән. Бу ислам өйрәтүләренә дә туры килә: бары тик Аллаһ ризалыгын гына өмет итеп бирелгән риясыз садака гомерне бәрәкәтле итә һәм ахирәттә зур шатлыкка әверелә. Шуңа күрә садаканың риясызлыгы төп шарт булып тора, аны кеше күзеннән яшереп бирү һәм хәтта ки биргәнеңне үзең дә онытырга тырышу өстен санала. Моңа өстәп тагын садаканың үз әһеленә бирелүе дә кирәкле-ген ассызыкларга кирәк булыр. Садака әһеле дип исламда гариплек, ятимлек, картлык зәгыйфьлеге сәбәпле мохтаҗлыкта яшәүчеләр атала. Байлыкка ия һәм үз ризыгын эшләп табарлык сәламәтлеккә ия булучылар садака әһелләреннән түгел. Боларга өстәп бары тик сау-сәламәт булса да, Аллаһның дине юлында тырышып, дөнья кәсебенә вакытлары калмаган мохтаҗ галимнәргә садака бирергә өндәлә Коръәннең "Бәкара" сүрәсе 273 нче аятендә. Ул галимнәрнең ачык билгеләре дә әйтелә: үзләре мохтаҗ булсалар да, сoранмыйлар. Гадәттә мондый галимнәрнең тагын бер әһәмиятле билгесе бар: дөнья малына кызыкмаганлыктан, ашарлык ризыклары булганда, биргәнне алмыйлар. Бу урында мәшһүр төрки әдибебез Сәиф Сараиның "Гөлстан-бит" төрки әсәреннән бер эпизодны хәзерге телгә күчереп сөйләп бирү урынлы булыр төсле.*

*Бер патша таң намазыннан соң, Аллаһы тәгаләдән дога кылып теләген сорый һәм теләге кабул булса, заһидларга (изгеләргә) булышырга вәгъдә бирә. Хак тәгалә аның теләген канәгатьләндерә. Патша инде догасының шартын күз алдында тотып, ышанычлы бер колына, изгеләргә хәер итеп өләш дип, янчык тулы алтын бирә. Кол, иртән китеп, кичкә янчыгы белән алтынны кире күтәреп кайта һәм: "Заһидларны тапмадым", – дип алтынны солтанга кире кайтара. Солтан моңа бик гаҗәпләнә, илендә дүрт йөз изге барлыгын колның исенә төшерә. Кол да зирәк була, солтанга: "Заһид булса алмый, алса – заһид түгел инде ул", – дип җавап кайтара. Кол изгелекнең, тәкъвалыкның чын асылын аңлаган кеше булып чыга. Аның тапкырлыгы каршылыклы җаваптан күренә: изге кеше дөнья малына кызыкмый, кызыга икән – изге түгел. Ул, әлбәттә, солтан йөкләгән вазифаны үтәп, алтынны өләшеп кайта алыр иде, әмма бу очракта шарт үтәлми, чөнки солтан алтынны заһидларга бирергә кушты. Бездә солтанның шушы колы кадәр акыл булса, милләттә садаканың шәригатьчә ысулы торгызылыр, әһеле булмаган кешегә садака тапшырып, соңыннан бу хакта шаулап йөрүче икейөзлеләр дә калмас иде.*

**Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ,**
**khayat.ru**



# "БАЛАЛАРЫ ЖӘЛ БИТ"

*Башыма яулык бөркәнеп йөри башлаганнан бирле үземә игътибар шактый артты бит әле. Кибеткә керсәм дә, базарга барсам да, кем дә булса туктатып, юк соравын бар итеп дигәндәй, минем белән сөйләшү җаен эзли башлый. Менә беркөнне күрше йорттагы даруханәгә кергәч тә шулай килеп чыкты. Дару сатучы ханым мине матур итеп татарча сәламләде, аннары, даруның монысы әйбәтрәк, тегесен алсагыз арзангарак төшә, дип киңәшләрен бирергә тотынды. Билгеле инде, мин дә ачылып киттем, бу чаклы дару эчкәч, безнең бөерләребез ни хәлдәдер инде, дип борчылуымны да белдереп куйдым. Шуны гына көтеп торган диярсең:*

*- И-и-и, безнең шул инде. Хәстәрендә генә торсаң да әле бер җирне, әле икенчесен эләктереп ала. Әнә безнең бакча күршебез Томаның балалары... - дип сузып җибәрде дару сатучы ханым. Мин исә тиз генә чыгып китә алмаячагымны аңлап, берәр танышы турындагы бик тә гыйбрәтле вакыйганы тыңларга әзерләндем. - Салкында да, карлы-яңгырлы көннәрдә дә минем алар өстендә рәтле кием күргәнем юк. Ашаулары такы-токы гына, ач итмибез инде, пешкән ризыктан аларга да өлеш чыгарабыз, балалары жәл бит... Шуларның авырганнарын түгел, төчкергәннәрен дә ишеткәнем юк. Алла үзе саклыйдыр инде аларны, минәйтәм. Ә Тома тәки теге "чир"еннән арына алмый. Совет заманында данлыклы бер кибеттә бүлек мөдире булып эшләгән ул. Шунда салгаларга өйрәнгән, диләр. Нәрсә майтаргандыр, беркөнне әнә "Перехват"тан күрсәттеләр үзен. Адресын сорыйлар - белми, үзе турында сөйләргә кушкач, дүрт балам бар, диде, ә исемнәрен әйтә алмады. Безнең Тома ич бу, дип барып алып кайттык. Менә сез дин юлында йөргән кеше, әйтегез әле миңа - нигә дип яшәтә икән Аллаһы тәгалә шундыйларны... Балалары жәл бит...*

*Мондый сораудан мин аптырап калдым. "Гыйбрәт өчен андыйлар да кирәктер инде бу җиргә", - диясем килгән иде дә, гыйлемем чамалы, гөнаһка батармын дип куркып, җавап биреп тормадым.*

**Рәйсә БОРҺАНОВА,**
**Казан**

# "ДОГАМ ӘРӘМ КИТТЕ"

**(Булган хәл)**

*Алтын көзнең кояшка туенып, яфракларның алтынсу төсләргә кереп, күзне камаштырырлык яктылык сибеп, җир өстенә чәчелгән мәле. Күңелдә, менә шушы яфраклар урынына алтын җәелеп ятсамы, дигән уй туды. Үз сүземә үзем ышанып яфраклар түгел, алтын тәңкәләр сибелгән парк эченнән атлыйм. Менә дөнья рәхәте! Чү, минем алдан барган әбекәй иелеп җирдән нәрсәдер алды. Аның һәр хәрәкәтен кызыксынып күзәтә башладым, кулында мең сумлык акча! Әби әллә төкеренде, әллә як-ягына каранды да акчаны җайлы гына бөкләп кесәсенә чумдырды. Аннан кыйбла ягына борылды бугай, ике учын ачып ашыкмый гына дога кылды. Кызык та, кызганыч та тоелды миңа. Кызыгы - алтын яфракларның акчага әйләнүе булса, кызганыч - миңа тиешле акчаны эләктерде бит. Күңелдә зилзилә бураннары кубарга да өлгермәде, минем дә алдымда мең сумлык пәйда булды. Әһә, бусын әби күреп өлгермәгән, дидем дә, акчаны тиз генә кесәмә тыгып, якындагы кибеткә юнәлдем. Бу шатлыклы мизгелләрне кичерү рәхәт иде миңа. Я, Аллам, дога кыла белмим, гафу ит. Их, теге яфраклар алтын ук булмаса да, акча булсачы... Минме нишләр идем? Катер, вилла, Париж...?! Иң беренче итеп шәп кенә күн куртка алыр идем. Мин бит саран-нардан түгел, шәһәрнең урта бер җирендә күз явын алырлык матур мәчет тә салдырыр идем. Алла биргәнне җәлләп торып булмас. Машина да кирәк әле. Кеше хатыннары кебек машинада җилдерәсем килә, дип хатын тәмам теңкәгә тия. Ипотекам искә төшкәч, йөрәк кысылып куйды. Ул мәлгуньнән котылыр көнем дә бар икән! Туктале, минем теге акча кесәдәме соң? Тәмәкегә дигән тимер акчалар янындагы мең сумлык уч төбемне җылытып җибәрде. Тукта, күзләремә якын куеп карыйм әле. Һәм ни күрим: акчаның икенче ягында кызыл төс белән язылган "Кулланышка яраксыз" дигән мәкерле сүзләр чекерәеп тора! Болай да уйнап торган кан басымым баш түбәмә үк сикерде. Әби дә кибеткә юнәлде түгелме? Йөрәкнең кагуыннан ничек барганымны да онытып, инде юл аша чыгарга өлгергән әбигә ташландым. Бәхеткә юлда машина-фәлән юк иде.*

*- Әбекәй, - дим, сулышымны чак-чак тыярга тырышып. - Акча таптың мәллә?*

*- Әйе шул, балакаем. Аллага шөкер. - Шул чак әбекәй нәрсәдәндер шикләнгәндәй, теге мең сумлыкны кесәсеннән чыгарып, беркемгә дә бирергә теләмәгәндәй, бөгәрләп учына кысты.*

*- Әбекәй, ул ялган акча, әйләндереп кара әле, - дим. Әбием калтыранган куллары белән акчаны кат-кат карады да: "Тфү, тфү, догам әрәм китте", - дип җиргә бәрде.*

**С.ТАҺИР**

# Ислам тәрбиясе – иң дөрес тәрбия

**Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм: "Бала дөньяга фитри иман белән килә. Әти-әнисе аны йә нәсари, йә яһүди, йә мөселман, яки бөтенләй динсез итә", - диде. Шулай шул, кеше иман белән туа, ә тәрбия һәм мохит аннан мөселман яки кәфер ясый: я яхшы, гадел кеше тәрбияли, я азгын, җинаятьче бәндә әзерләп чыгара.**

Яхшы, гадел бала дигәнебез дә, әгәр аңа дини тәрбия бирелмәсә, бозык кешеләр арасына эләгеп, юлдан язарга, харап булырга да мөмкин. Бүген нәкъ менә шул хәл күзәтелә дә инде. Ата-ана баласын ашата-эчертә, киендерә, кулыннан килгәнчә дөньяви белем, һөнәр алырга ярдәм итә... Көннәрдән бер көнне кадерләп үстергән баласының наркоман, фахишә, эчкече, карак, җинаятьче бер бәндәгә әверелүен күреп, телсез кала. Бүген ике гаиләнең берсендә шушы фаҗига, ике баланың берсе һәлакәт чигендә. Татарстанда гына да һәр көнне бер кеше үз-үзенә кул сала. Бу иман белән дөньяга килгән кеше, кәфер булып, җәһәннәмгә күчә дигән сүз...

Соңгы бер ел эчендә, җенси авырулар белән чирләүчеләр саны берничә тапкыр арткан. Илнең кайбер төбәкләрендә үлүчеләр саны 1941-1945 елгы дәрәҗәгә җиткән. Тагын бик күп шундый гыйбрәтләрне санарга булыр иде. Болар барысы да җәмгыятебез тәрбиясе, дөресрәге, тәрбиясезлек җимешләре. Тәрбия турында нинди фәнни тикшеренүләр генә уздырылмый, хезмәтләр язылмый да нинди генә чаралар уздырылмый. Әмма боларның берсе дә ислам тәрбиясе биргән нәтиҗәне бирә алмый.

Җир йөзендә берсе икенчесенә охшамаган җиде миллиардтан артык кеше яши. Җиде миллиард төрле холык-фигыль... Шуларның кайсысын яхшы дип санарга? Ата-анасына әйбәт мөгаләмәдә булып та, күршесен рәнҗеткән яисә ятимнәргә ярдәм итүче, ләкин гаиләсенә карата тиран булган агайны өлге итеп куяргамы? Нинди була соң ул яхшы тәрбия һәм камил кеше? Адәм баласын барлыкка китергән Аллаһы тәгалә аның нинди булырга тиешлеген дә белгән, шуңа күрә кеше белән бергә аның өчен тәртип кагыйдәләрен дә барлыкка китергән. Кешелек өчен кагыйдәләр тупланмасы - ул Коръән, пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең сөннәте. Коръән һәм хәдисләрнең өчтән бере - кеше күңеле, холкы, кешенең яхшы һәм начар сыйфатлары, башкалар белән мөнәсәбәтләре турында. Аларда яхшы кеше тәрбияләүнең барлык серләре дә бар. Шуңа да яхшы кеше үрнәген бары тик ислам динендә генә табарга була, чөнки ул бөек Аллаһның күрсәтмәләре буенча яши.

Ләкин бу һәр мөселман - камил кеше, дигән сүз түгел. Коръән кануннарыннан тайпылмыйча яшәүче, гөнаһсыз, камил кеше, мөгаен, юктыр да. Әмма кечкенәдән ныклы дини тәрбия алган бала, киләчәктә гөнаһлар эшләмичә, саваплы гамәлләр генә кылырга тырыша. Ә яхшыга омтылу - үзе савап ул.

**Мәрьям АБДУЛЛИНА,**
**КФУ студенты**

# Ә СЕЗ НИЧЕК ЯЛ ИТӘСЕЗ?

**Балагызның кышкы каникулларны мавыктыргыч һәм файдалы уздыруын телисезме? Ул чагында республикабыз мәчет-мәдрәсәләрендә ачылачак кышкы лагерьларга рәхим итегез.**

Түбәндә без декабрь уртасына алынган мәгълүматларны җиткерәбез. Исемлектә үз мәхәлләгезне таба алмасагыз, артык хафаланмыйча, имамнарга мөрәҗәгать итегез. Соң булса да уң булсын, дигәндәй, бәлки, матди җай чыгып, алар да бу изге эшкә кушылганнардыр.

Хәер, балаларның ялын кайгыртуның башка ысулларын уйлап табучы мәхәлләләр дә бар. Аксубайда, мәсәлән, алар өчен викторина үткәрергә булганнар. Ә Тукай, Минзәлә, Кайбычта исә ел дәвамында алып барыла торган курсларны төрле турнирлар, уеннар белән төрләндереп җибәрергә уйлыйлар.

***Каникулларны файдалы һәм җанлы итеп үткәрүнең тагын кайсы төбәктә нинди ысулларын тапканнар - шул хакта безгә дә язып җибәрегез (naubahar67@list.ru).*** Ә без бик рәхәтләнеп матур башлангычыгызны бөтен республикага таратырбыз.

## КЫШКЫ ЯЛЛАРДА КАЙСЫ МӘХӘЛЛӘДӘ БАЛАЛАР ӨЧЕН ЛАГЕРЬЛАР АЧЫЛА

| Мөхтәсибәтләр | Мәчет/мәдрәсә | Кемгә мөрәҗәгать итәргә |
|---|---|---|
| **Азнакай** | Ак мәчет (Ш.Мәрҗани ур., 41) | |
| **Алабуга** | җамигъ мәчет (Тынычлык просп., 2) | Әзмәл хәзрәт САМАТОВ, тел.: 89600789929 |
| **Актаныш** | җамигъ мәчет (Советская, 22а) | Руслан хәзрәт МОРТАЗИН, тел.: 89372834680 |
| **Әлмәт** | җамигъ мәчет (Ш.Мәрҗани ур., 82 а), кызлар өчен | |
| **Апас** | Миргасыйм мәчете (М.Җәлил ур., 38) | Мирхәт хәзрәт ҖАМАЛИЕВ, тел.: 89061159331 |
| **Әтнә** | җамигъ мәчет (Татарстан ур., 7) | Наил хәзрәт СӘГЪДИЕВ, тел.: 89600382376 |
| **Балык Бистәсе** | Тәб.Чаллы, Биектау авылы мәчетләрендә | |
| **Баулы** | Өмет мәчете (Татарстан ур., 1а) | |
| **Буа** | мәдрәсәдә (К.Либкнехт, 79) | Илмир хәзрәт ХӘСӘНОВ, тел.: 89270382582 |
| **Бөгелмә** | җамигъ мәчет (Краснослободская, 68) | тел.: 8(85594) 41698 |
| **Зәй** | җамигъ мәчете (Т.Ялчыгол ур., 16), Аксар мәчете | Сәгыйть хәзрәт КАМАЛОВ, тел.: 89178515250 |
| **Казан** | Гаилә мәчете (Ж.Фәйзи ур.,2) | Тел.: 2230662 |
| **Кама Тамагы** | җамигъ мәчет (Гагарин ур., 5) | Галимулла хәзрәт ЯРУЛЛИН, тел.: 89063296027 |
| **Мамадыш** | мәдрәсәдә (М.Җәлил ур., 28) | Илһам хәзрәт МИННЕГАЛИЕВ, тел.: 89196352943 |
| **Менделеев** | җамигъ мәчет | Ирек хәзрәт НУРИЕВ, тел.: 89870085641 |
| **Сарман** | Җамигъ (К.Тинчурин ур., 55а) | Сәгыйть хәзрәт ХАКОВ, тел.: 89196388877 |
| **Түбән Кама** | җамигъ мәчеттә, Яңа мәчеттә, “Ихлас” мәркәзендә (кунып яши торган лагерьлар) | |
| **Чирмешән** | җамигъ мәчет | Минсәгыйр хәзрәт МИНШИН, тел.: 89274289196 |
| **Югары Ослан** | җамигъ мәчет (Төзүчеләр ур., 6а) | Гали хәзрәт ҖИҺАНШИН, тел.: 89274421742 |
| **Ютазы** | Кече Авыл мәчетендә, 2 нче Урыссу мәхәлләсендә | Марат хәзрәт МӘРДАНШИН, тел.: 89172658738 |
| **Яшел Үзән** | мәдрәсәдә (Ленин ур., 22а) | тел.: (8843) 7140473 |
| **Яңа Чишмә** | җамигъ мәчет | Газизулла хәзрәт ЗАРТДИНОВ, тел.: 89872743411 |



# САКАЛЫНА КАРАП ФИКЕР ЙӨРТМӘГЕЗ

***Гаилә кору Пәйгәмбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең сөннәте булып тора. Никах һәрбер мөселманның тормышында мөһим вакыйга. Үзеңә пар сайлау бик җаваплы эш, ләкин моны күбебез аңлап бетерми әле.***



Бервакыт мәчеткә барганда мин бер мөслимә белән таныштым. Юл озын булу сәбәпле, аның белән төрледән-төрле темаларга сөйләшеп бардык. Мин үзем турында, ә ул үзе турында сөйләде. Яшь булуына карамастан, бик күп сынаулар аша үткән икән.

- Сиңа гыйбрәт булсын дип сөйлим, - дип башлады ул сүзен. - Элек мин мөселман гаиләләренә кызыгып карый идем, үземнең дә аларныкы шикелле бәхетле оя корасым килә иде. 22 яшь тулгач, танышларым мине бер егет белән таныштырдылар. Аның да нияте чын мөселман гаиләсе корып, хәләл җефетен бары тик өйдә генә утырту икән. Безнең очрашуны ул кафеда билгеләде, бары тик вәли катнашында гына очрашырга дигән шарт та куйды. Мин, әлбәттә, каршы килмәдем. Очраштык, күземә бөтенләй карамый, оялып кына сөйләшә бу. Дөресен әйткәндә, тышкы кыяфәте белән башта бер дә ошамады, ә менә үз-үзен тотышы күңелемне шундук җәлеп итте. Тик никтер ул минем тормышым белән бөтенләй кызыксынмады, бу бераз сәеррәк тоелды, чөнки мөселман егетләре гадәттә булачак хатынының барлык якларын тишерергә тырыша бит. Икенче очрашуда ук ул миңа тәкъдим ясады. Танышларның аның турында "яхшы кеше" дигән сүзләре дә тәэсир иткәндер инде - ризалаштым. Әни белән әти, бик тиз түгелме, дип шикләнделәр үзе, мин алар сүзенә колак салмадым. Аллаһ ризалыгы өчен яратып, гаилә корырга булдым.

Никах бик әйбәт үтте, без шундук иремнең фатирына кайтып киттек. Эчемнән сөенсәм дә, күңелемә нидер тынгы бирмәгән сыман тоелды. Шөбһәләнүем бер дә юктан булмаган икән шул. Өйгә кайтуга ирем минем белән дорфа сөйләшә, һәрбер сүземә бәйләнә башлады. Моны дөрес эшләмисең, тегене менә болай эшләргә кирәк, дип өйрәтергә үк тотынды. Ә мин, шулай булырга тиештер, дип уйладым. Икенче көнне үк миңа кул күтәргәч, тәмам аптырап калсам да - түздем, дөресрәге, бу хакта әти-әниемә әйтергә хурландым. Бер ай шулай кыен ашаганнан соң, түземлегем бетте, әйберләремне җыеп әниләргә кайтып киттем. Кияүдә булган ул көннәремне начар төш кебек онытырга тырыштым, иң мөһиме - мин аннан котылдым, дип уйладым. Әмма бу әле тартышның башы гына булган икән - ирем талак бирми. Мин аерылганмы, әллә әле һаман да ир хатыны саналаммы - белмим.

... Яңа танышым сөйләгәннәрне тыңлагач, әллә ничә көн буе авыр хис-тойгылар белән йөрдем. Инде менә газетага яздым, башкаларга гыйбрәт булсын әле. Кызлар колагына киңәш итеп әйтәм: мөселманнар турында сакалына, намаз укуына гына карап фикер йөртмәгез. Утырып калабыз дип куркып, бер белмәгән кеше белән язмышыгызны бәйләргә дә ашыкмагыз. Шулай да кияүгә чыгарга уйлагансыз икән, оялып тормагыз, булачак ирегез турында аның күршеләренә, туганнарына барып сорашыгыз. Бу шәригать канунарына һич тә каршы килми дип беләм.

*Ләйсәнә ИЛЬЯСОВА*

# КУЛЫННАН ГЫНА ТОТСАМ ЯРЫЙМЫ?

***Дурр әл-Мохтар, Шифа әш-Шәриф, Бохари, имам Гайнинең Бохарига шәрехендә болай дип китерелә:***

Фетнә һәм гөнаһ кылуны китереп чыгармау максатыннан кыз балага ир-атлар каршында йөзен ачарга ярамый. Ир-атның үз шәһвәтен тыеп тора алуда ышанычы ныклы булуга да карамастан, аңа барыбер хатын-кызның кулына һәм йөзенә кагылу рөхсәт ителми.

Кагылу - карап торудан көчлерәк, шунлыктан шәһвәтне тыеп тора алуда ышаныч булганда - карау тыелмый, ә чит хатын-кызның тәненә кагылу - һәр очракта да тыела.

Нәдыр ибне Хәрес (радияллаһу ганһү): "Пәйгамбәрнең (салләллаһу галәйһи үә сәлләм) кулы, үзенә хәләл булганнарыннан (хатыннары һәм җарияләреннән) тыш, бүтән бер хатын-кызның да тәненә тимәде", - дип әйтә.

Гүрвә (радияллаһу ганһү) Гайшәнең (радияллаһу ганһә) түбәндәге сүзләрен җиткерә: "Хатын-кызлар "Мүмтәхәнә (сыналучы хатын)" сүрәсендә әйтелгән сыналу шартларын кабул итеп, бәйгать биргәндә Аллаһның рәсүле (салләллаһу галәйһи үә сәлләм) көчле нотыктан соң: "Мин синең бәйгатеңне кабул иттем!" - диде. Аллаһ белән ант итәм, Аллаһның рәсүле (салләллаһу галәйһи үә сәлләм) бәйгать кабул иткәндә бер генә хатын-кызга да кулы белән кагылмады, ул бәйгатьне телдән генә кабул итте" (Бохари. Китаб әш-Шүрутъ: 1,2/967, №2564).

*"Шура", №5*



# ИСЕМЕҢ ЯМЬСЕЗ, КЕМНӘР КУЙГАН?

***Ата-ана үз баласына исем сайлаганда аның яңгырашына гына игътибар итеп калмыйча, нинди мәгънәгә ия булуы белән дә кызыксынырга тиеш. Юкса үзең дә теләмәстән йөрәк парәңә шайтан исеме кушып куюың ихтимал.***

Шайтан ул - Аллаһның бер мәхлугы булгач, аның да исеме бар икәне көн кебек ачык. Берзаман Гомәр (р.г.) янына Мәсрук дигән кеше килә. Гомәр (р.г.) аңардан: "Исемең ничек?" - дип сорый, тегесе: "Мәсрук" дип җавап бирә. Гомәр (р.г.) янә: "Әтиеңнең исеме ничек?"- дип сорый. Ул: "Әл-Әҗдаг" дип җавап кайтара. Гомәр (р.г.) аңа: "Әл-Әҗдаг - шайтан исеме, шулай ук Хәнзәб тә, Әл-Вәлһән дә шайтан исемнәре. Шайтан исемнәрен кешегә кушарга ярамый", - дип аны кисәтә.

Иблиснең балаларының да исемнәре булган:

1. Хаффәф - аның вазыйфасы кешеләрне куркыту һәм газаплау, ул куркыныч хайваннар сурәтенә кереп куркыта.
2. Зәләнбур - бусы базардагы Иблис баласы. Ул анда алдап сатучыларның гамәлләрен зиннәтләп күрсәтә.
3. Вәлһә - "Таһарәтең дөрес түгел, намазыңны камил укымадың", - дип вәсвәсә кылып, яңадан укырга кушучы.
4. Әбяз - пәйгамбәрләргә вәсвәсә кылучы.
5. Сәбр.
6. Әгуар - кешенең шәһвәтен кузгатучы. Кызларга егетләрне, егетләргә кызларны күрсәтеп шәһвәтләрен уята һәм зинага өнди.
7. Дәсим - өйдә ир белән хатын арасында фетнә чыгарырга өндәүче.
8. Матраш - ялган хәбәр таратучы.
9. Дәһһәр - мөэминнәргә начар төшләр күрсәтеп азаплаучы.
10. Тәмрих - намазны укыттырмау һәм башка фарыз-вәҗибларны үтәтмәү өчен тырышучы.
11. Ләкис - хатыннар белән хатыннарны зина кылдыручы.
12. Иклас - казиноларда һм башка җирләрдә акчага уйнарга өндәүче.
13. Акбаз - йомырка салып шайтаннарны арттыручы.

# ШӘРИГАТЬ КОНТРАЦЕПЦИЯ ЧАРАЛАРЫН КУЛЛАНУНЫ РӨХСӘТ ИТӘ, ӘММА...

1. Балага узудан саклану чараларын (таблеткалар, презервативлар һ. б.) кулланырга ярый.

"Әл фикъһел исләми вә гаддиләтүһ" китабының (III том) 555 нче битендә бу уңайдан болай диелгән: "Шуңа нигезләнеп, авырга узудан саклаучы таблеткалар һәм шуңа охшаш заманча чараларны куллану рөхсәт ителә, ләкин алар бүтән авырга узу һәм бала табу мөмкинлеген гомумән юкка чыгарырга тиеш түгел. Әз-Зәркаши болай дигән: "Газел" (йөклелекне өзә торган дарулар вә чаралар куллану) вакытлыча рөхсәт ителә, ләкин ул бөтенләйгә авырга узуны югалту очрагында рөхсәт ителми".

2. Әни кешенең яки туачак баланың сәламәтлегенә куркыныч янаса, 120 нче көнгә кадәр йөклелекне өзү рөхсәт ителә, әгәр сәламәтлеккә куркыныч янамаса, йөклелекне өзү - мәкруһ тәхрими (хәрам) гамәл булып тора һәм бу - гөнаһ санала.

"Рәддел-мохтәр" китабының (II том) 412 нче битендә болай диелгән:

"Әлхания" китабының карахият (хупланмый торган гамәлләр) турындагы бүлегендә болай дип әйтелә: "Мин моны хәләл (рөхсәт ителгән) дип әйтмим, чөнки мөхрим (ихрамга керүче һәм хаҗ кылучы) кош йомыркасын ватса, ул аның өчен штраф түләргә тиеш, чөнки ул йомыркадан кош чыга; мөхрим бер йомырка өчен генә җәзага тартылганны, йөклелекне бер сәбәпсез (сәламәтлеккә зыяны булган кебек) өзгән кешегә - аз дигәндә, гөнаһ була да инде..."

"Әз-Заһира" китабы түбәндәгеләрне җиткерә: "Яралгыга җан өрелгәнче (120 нче көнгә кадәр) йөклелекне өзәргә ярыймы? Монда фикер төрлелеге күзәтелә. Факиһ Гали ибн-Муса моны мәкруһ булып тора дип әйткән, чөнки мәни күкәй күзәнәккә эләккәннән соң тормыш башланды дигән сүз, аның хөкеме - тере булу (хаҗ вакытында Мәккәдә хаҗиларга хәрам кош йомыркасы кебек)". Бу мәгълүматлар "Әззаһирия" китабында да бар.



Ибн Вәһбан болай дигән: "Акланырлык сәбәп (әни кешенең яки туачак баланың сәламәтлегенә куркыныч) булса - йөклелекне өзү рөхсәт ителә, әгәр андый сәбәп булмаса - ул гөнаһлы була, әмма бу гөнаһның дәрәҗәсе кеше үтергән кебек үк түгел".

3. 120 нче көннән соң йөклелекне өзү хәрам гамәл булып санала.

Аллаһыга яхшырак билгеле.

*Мөфти Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН*

# Чын мөэмингә хас сыйфатлар

**Имам әш-Шәһрестани (һиҗри белән 479-548 нче еллар / милади белән 1087-1154 нче еллар) болай дигән: "Шуны бел: күп сәләфләр Аллаһы тәгаләне гыйлем, кодрәт, тормыш, ихтыяр, ишетү, күрү һәм сөйләм сәләтләре, рәхимлелек, куәт кебек, баштан ук бакый сыйфатлар белән тасвир иткән.**

Күндәмлек - Аллаһы тәгаләнең Үз колларына ирештергән бәяләп бетергесез олуг рәхмәте. Күндәмлек ул - зирәклек чагылышы. Күндәмлек ул - шуны аңлау: һәр кешегә ниндидер сәләт бирелгән, ул кеше андый сыйфатларын бар дөнья белән уртаклашырга тиеш, тик бу вакытта һәркем Аллаһы яралткан күптөрле кешеләрнең берсе генә булып тора һәм һәр кешегә дә Аллаһы билгеле бер мөһим роль башкаруны тәкъдир иткән.

Күндәмлек турында сүз алып барып, Аллаһы тәгалә әйтә: "Вә үзеңә ияргән мөэминнәргә рәхмәт канатыңны җәй (аларга карата миһербанлы бул)" ("Шүгәраү (Шагыйрьләр)" сүрәсе, 215 нче аять).

Аллаһы безнең барыбызга да күндәм булырга хөкем кылган. Ата-аналарга карата күндәм булу турында Коръәндә әйтелгән: "Вә аларга шәфкать итеп, рәхим канатларыңны җәйгел! Вә әйт: "Ий Раббым, алар мине кечкенә чагымда мәрхәмәт белән үстергән кебек Син дә аларга дөньяда һәм ахирәттә шәфкать кыйл" ("Бәни Исраил (Ягъкуп балалары)" сүрәсе, 24 нче аять). Аллаһының рәсүле (аңа Аллаһының салаваты вә сәламе ирешсә иде) әйткән: "Чынлап та, Аллаһы миңа шундый эчтәлекле вахи иңдерде: сезгә күндәмлек күрсәтергә кирәк, беркем дә икенче берәү каршында мактанмасын һәм дә икенче берәүне җәберләмәсен".



Аның икенче бер хәдисендә болай диелә: "Аллаһы ризалыгы өчен күндәмлек күрсәткән теләсә кайсы кешенең Кодрәтле һәм Бөек Аллаһы Үз каршында дәрәҗәсен күтәрер".

Күндәмлек күрсәтүнең идеаль үрнәге - сөекле пәйгамбәребез (аңа Аллаһының салаваты вә сәламе ирешсә иде). Чынлап та, әгәр аның тормышына карасак, ул кем белән генә аралашса да, кем белән генә эш исә дә, һәрвакыт күндәмлек күрсәтә торган булган.

Күндәмлек - Аллаһы тәгаләнең аның турында бар сөйләнгәннәрдән дә чиксез зур, кеше гакылы ирешмәслек дәрәҗәдә булуын аңлау ул. Күндәм кеше сирәк бер камиллек белән бөек эшләр башкаруга сәләтле, чөнки аны үз мәнфәгатьләре яки репутациясе кебек вак-төяк мәсьәләләр борчый алмый.

Бу тормышта безнең башка төшкән бар әйберләр дә - шатлыклар да, кайгы-борчулар да - безне сынау өчен җибәрелә. Шулай итеп, без бу фани дөньяда имтихан тотабыз. Мондый очракларда Аллаһыга мөрәҗәгать итәргә, Аның ризалыгын алу турында уйларга; шатлык килгән чакларда - Раббыбызга шөкер итәргә, кайгы-хәсрәт килгән чакларда - Аннан көч һәм ярдәм сорарга, күндәмлек күрсәтергә кирәк.

Аллаһыга ялвару, Аның каршында күндәмлек күрсәтү - иң бәрәкәтле эшләрнең берсе. Бу ике әйбер һәм сынауларны лаеклы үтеп чыга белү - динне дөрес тоту билгесе булып тора. Чөнки динне дөрес итеп тота белү - Аллаһыга гыйбадәт кылуны, Аңа сыгынуны, Аннан башка беркемгә дә гыйбадәт һәм дога кылмауны (гыйбадәт кылу догасымы, әллә инде Аллаһыга ялварып дога кылумы) аңлата.

## МӘЧЕТТӘ ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТОТУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

***Фәкыйһ Әбү Ләес Әс-Сәмәрканди (Аллаһы тәгалә аннан разый булсын) үзенең "Тәнбиһел-Гафилин" китабында мәчеткә карата унбиш төрле хөрмәткә лаек гамәл бар дип искәртә:***

1) мәчеткә кергәч, анда утырып торган, дәрес алмаган яки зикер әйтү белән шөгыльләнмәгән кешеләргә сәлам бирергә кирәк. Әгәр мәчеттә беркем дә булмаса яки анда булган кешеләр намаз укыса, "Әс-сәламү галәйнә мир-Раббинә үә галә гыйбадиЛләхис-Салихин" (Тәрҗемәсе: "Раббыбыз исеменнән һәммәбезгә һәм Аллаһның бар тәкъва колларына иминлек булсын") дип әйтелә;

2) кереп утырганчы ике рәкәгать "Тәхиятел-Мәсҗид" намазы (мәчетне сәламләү намазы) укырга кирәк;

3 ) мәчеттә сату-алу белән шөгыльләнмәскә, тиҗарәт (сәүдә) эшләре алып бармаска;

4) әгәр үзең белән корал булса, аны чыгармаска;

5) югалткан әйберне эзләмәскә;

6) Аллаһка зикер әйтүдән тыш, тавышыңны күтәреп сөйләшмәскә;

7) мәчеттә дөнья хәлләрен сөйләмәскә;

8) утырган кешеләр өстеннән атлап чыкмаска;

9) урын өчен бәхәсләшмәскә;

10) намаз укыганда үзең белән бер рәттә торганнарны кысрыкламаска;

11) намаз укучылар алдыннан үтеп йөрмәскә;

12) төкерегеңне чәчмәскә;

13) бармак шартлатып яисә шакылдап утырмаска;

14) кечкенә балалар һәм акылга зәгыйфь кешеләр намаз уку урыннарына йомышларын үтәп куйса, аны чистартырга;

15) Аллаһы тәгаләгә күбрәк зикер әйтергә.

"Әл-Гарәиб" китабында да шундый ук мәгълүматлар китерелә.

***Татарстан мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН***



# МӘЗҺӘБЛӘРГӘ ИЯРҮ – СӘЛӘФЛӘР ЮЛЫ

Безнең заманда ялган сәләфитләр сектасы мәзһәбләргә сукырларча иярүдән баш тартырга өнди, моның урынына алар "ышанычлы хәдисләргә" таянырга чакыралар һәм моны ата-бабалардан килгән ышанычлы ысул итеп күрсәтәләр.

Түбәндә Ислам диненең беренче 3 гасырындагы бөек галимнәрдән цитаталар китерәбез. Алар хәдиснең кулланылуы өчен аның ышанычлылыгына дәлил булу гына җитмәвен ачык әйтәләр.

Мөхәммәд әш-Шайбани, рәһимахуллаһ, болай дигән: "Хәдисне фикыһтан башка кулланып булмый, һәм хәдискә таянмыйча гына фикыһ та була алмый".

Имам Әхмәд болай дигән: "Диндә тәкълидкә урын юк диючеләр Аллаһы тәгалә һәм аның Пәйгамбәре каршында фасикълар, чөнки аларның сүзләре Сөннәтнең, сахабәләр һәм табигыйннар мирасының юкка чыгуына, Сөннәтнең һәм белемнең бушап калуына, һәр кешенең үз фикере булуына, яңалыклар һәм фикерләрдә аермалыклар килеп чыгуга китерә. Ә мәзһәбләр һәм мин искә алган фикерләр - барысы да Әһле сөннәт вәлҗәмәгать, безгә белемне җиткергән хәдис кешеләреннән. Без алардан хәдисне алып, Сөннәтне өйрәндек. Алар - имамнар һәм ышанычка, алар артыннан иярүгә һәм алар фикеренә таянуга лаек кешеләр. Алар бидгать кертү яклы булмаганнар. Алар безгә кадәр яшәгәннәр, аларга ияреләргә һәм алардан өйрәнергә кирәк. Ә тәүфикъ Аллаһы тәгаләдән".

Шулай итеп, бөек имам диндә тәкълидне кире кагарга ярамавы һәм һәр кеше, өммәт фәкыйһлары мирасына игътибар бирмичә, хәдисләрне һәм Сөннәтне үзенчә аңлый ала, дип әйтергә ярамавы турында әйтә. Бу ялгыш фикер, чөнки ул белемне бетерә.

Шулай ук имам Әхмәд болай дигән: "Кеше алдында Пәйгамбәр, сахабәләр һәм табигыйннар сүзләре язылган китап булса, аңа үзе теләгән һәм үзе сайлаганга иярергә ярамый. Ул бу хәдис турында белем кешеләреннән сорарга тиеш - бу хәдискә ышанырга буламы әллә юкмы, шуннан соң гына аның иярүе дөрес булачак".

Әл-хафиз Әбел-Хәсән әл-Маймуни тапшыра: "Бервакыт имам Әхмәд миңа болай диде: "И, Әбел-Хәсән, имамың булмаган сорау буенча фикереңне әйтүдән тыел".

Имам әз-Захаби түбәндәге сүзләргә "Сияр"дә тәфсир бирә: "Хәдискә иярү Әбү Хәнифә яки Шәфигый фикеренә иярүгә караганда яхшырак": "Бу яхшы фикер, ләкин бу хәдис буенча имам Әбү Хәнифә һәм Шәфигыйга тиң имамнар фикерләрен әйтергә тиеш. Мәсәлән: Малик, Суфиян, Ләес. Шулай ук хәдис ышанычлы һәм эчке кимчелекләрдән азат булырга тиеш. Имам Әбү Хәнифә һәм Шәфигый таянган хәдисне кире кагучы хәдис булырга тиеш түгел. Ә имамнар фикеренә игътибар итмичә ышанычлы хәдисне кулланырга рөхсәт ителми".

Ибне Рәҗәб әл-Хәнбәли болай дигән: "Әһле-хәдис имамнары һәм факихлары сахабәләр һәм алардан соң булган кешеләр кулланган ышанычлы хәдисләргә генә таяналар. Әгәр дә сәләфиләр ниндидер хәдискә иярмәскә дигән фикергә килгәннәр икән, бу хәдискә, ул ышанычлы булса да, иярергә ярамый. Чөнки алар аны куллanудан туктаганнар икән, димәк, аларның моңа сәбәпләре булган. Гомәр ибне Габдел-Газиз болай дигән: "Сезгә кадәр булганга туры килгән фикергә таяныгыз. Алар сездән күбрәк белгәннәр".

Шулай ук Ибне Рәҗәб болай дигән: "Безнең заманда Шәфигый, Әхмәд, Исхак һәм башка сәләф-имамнарның фикерләре билгеле булган, һәм кешеләр алардан соң килгәннәрдән сакланырга тиеш, чөнки алардан соңгылар үзләрен Сөннәт дип исәпләгәннәр, ә чынлыкта исә, имамнар фикереннән ерак китүләре сәбәпле, Сөннәткә каршы килгәннәр. Алар имамнар әйтмәгән фикерләрне әйткәннәр һәм имамнар таянмаган хәдисләргә таянганнар".

Бу сүзләр соңгы ике галим сүзләре булса да, аларда бик күп файда бар һәм алар бу өлкәдә сәләф-имамнар фикеренә тулысынча туры киләләр.

***Рәшид ИСАЕВ***

## 2015 ЕЛДА МӨСЕЛМАН БӘЙРӘМНӘРЕ ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ КӨННӘР

**3 нче гыйнвар (шимбә) - Мәүлид бәйрәме.**
**21 нче гыйнвар (чәршәмбе) - рабигылахыр аеның беренче көне.**
**20 нче февраль (җомга) - җөмадиәләүвәл аеның беренче көне.**
**21 нче март (шимбә) - җөмадиәлахыр аеның беренче көне.**
**20 нче апрель (дүшәмбе) - рәҗәп аеның беренче көне.**
**23 нче апрель (пәнҗешәмбе) - Рәгаиб кичәсе.**
**24 нче апрель (җомга) - Рәгаиб кичәсе көне.**
**15 нче май (җомга) - Мигъраҗ кичәсе.**
**16 нчы май (шимбә) - Мигъраҗ кичәсе көне.**
**19 нчы май (сишәмбе) - шәгъбан аеның беренче көне.**
**1 нче июнь (дүшәмбе) - Бәраәт кичәсе.**
**2 нче июнь (сишәмбе) - Бәраәт кичәсе көне.**
**17 нче июнь (чәршәмбе) - рамазан аеның беренче көне.**
**12 нче июль (якшәмбе) - Кадер кичәсе.**
**16 нчы июль (пәнҗешәмбе) - рамазан аеның соңгы көне.**
**17 нче июль (җомга) - Ураза бәйрәме (шәүвәл аеның беренче көне).**
**16 нчы август (якшәмбе) - зөлкагдә аеның беренче көне.**
**14 нче сентябрь (дүшәмбе) - зөлхиҗҗә аеның беренче көне.**
**22 нче сентябрь (сишәмбе) - Гарәфә көне.**
**23 нче сентябрь (чәршәмбе) - Корбан бәйрәме.**
**14 нче октябрь (чәршәмбе) - мөхәррәм аеның беренче көне (һиҗри исәп белән яңа ел башлану).**
**23 нче октябрь (җомга) - Гашүрә көне.**
**13 нче ноябрь (җомга) - сафәр аеның беренче көне.**
**12 нче декабрь (шимбә) - рабигыләүвәл аеның беренче көне.**
**22 нче декабрь (сишәмбе) - Мәүлид кичәсе.**
**23 нче декабрь (чәршәмбе) - Мәүлид бәйрәме.**

## ГЫЙНВАР АЕНА КАЗАНДА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Таң беленә башлый | Мәчетләрдә укыла | Кояш чыга | Өйлә Намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы | Кыбла |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 01.01.2015 | 05:53 | 06:43 | 08:13 | 12:00 | 13:33 | 15:20 | 17:18 | 12:51 |
| 02.01.2015 | 05:53 | 06:42 | 08:12 | 12:00 | 13:34 | 15:22 | 17:19 | 12:52 |
| 03.01.2015 | 05:53 | 06:42 | 08:12 | 12:00 | 13:35 | 15:23 | 17:20 | 12:52 |
| 04.01.2015 | 05:52 | 06:42 | 08:12 | 12:00 | 13:37 | 15:24 | 17:21 | 12:53 |
| 05.01.2015 | 05:52 | 06:41 | 08:11 | 12:00 | 13:38 | 15:25 | 17:22 | 12:53 |
| 06.01.2015 | 05:52 | 06:41 | 08:11 | 12:00 | 13:39 | 15:27 | 17:23 | 12:53 |
| 07.01.2015 | 05:52 | 06:40 | 08:10 | 12:00 | 13:41 | 15:28 | 17:25 | 12:54 |
| 08.01.2015 | 05:51 | 06:39 | 08:09 | 12:00 | 13:42 | 15:30 | 17:26 | 12:54 |
| 09.01.2015 | 05:51 | 06:39 | 08:09 | 12:00 | 13:43 | 15:31 | 17:27 | 12:54 |
| 10.01.2015 | 05:51 | 06:38 | 08:08 | 12:00 | 13:45 | 15:33 | 17:28 | 12:55 |
| 11.01.2015 | 05:50 | 06:37 | 08:07 | 12:00 | 13:46 | 15:35 | 17:30 | 12:55 |
| 12.01.2015 | 05:50 | 06:36 | 08:06 | 12:00 | 13:48 | 15:36 | 17:31 | 12:55 |
| 13.01.2015 | 05:49 | 06:35 | 08:05 | 12:00 | 13:50 | 15:38 | 17:32 | 12:56 |
| 14.01.2015 | 05:48 | 06:34 | 08:04 | 12:00 | 13:51 | 15:40 | 17:34 | 12:56 |
| 15.01.2015 | 05:48 | 06:33 | 08:03 | 12:00 | 13:53 | 15:42 | 17:35 | 12:56 |
| 16.01.2015 | 05:47 | 06:32 | 08:02 | 12:00 | 13:55 | 15:44 | 17:37 | 12:56 |
| 17.01.2015 | 05:46 | 06:31 | 08:01 | 12:00 | 13:56 | 15:45 | 17:38 | 12:56 |
| 18.01.2015 | 05:45 | 06:30 | 08:00 | 12:00 | 13:58 | 15:47 | 17:40 | 12:57 |
| 19.01.2015 | 05:45 | 06:28 | 07:58 | 12:00 | 14:00 | 15:49 | 17:41 | 12:57 |
| 20.01.2015 | 05:44 | 06:27 | 07:57 | 12:00 | 14:02 | 15:51 | 17:43 | 12:57 |
| 21.01.2015 | 05:43 | 06:26 | 07:56 | 12:00 | 14:03 | 15:53 | 17:45 | 12:57 |
| 22.01.2015 | 05:42 | 06:24 | 07:54 | 12:00 | 14:05 | 15:55 | 17:46 | 12:57 |
| 23.01.2015 | 05:41 | 06:23 | 07:53 | 12:00 | 14:07 | 15:57 | 17:48 | 12:57 |
| 24.01.2015 | 05:40 | 06:21 | 07:51 | 12:00 | 14:09 | 15:59 | 17:49 | 12:57 |
| 25.01.2015 | 05:38 | 06:20 | 07:50 | 12:00 | 14:11 | 16:01 | 17:51 | 12:58 |
| 26.01.2015 | 05:37 | 06:18 | 07:48 | 12:00 | 14:13 | 16:03 | 17:53 | 12:58 |
| 27.01.2015 | 05:36 | 06:16 | 07:46 | 12:00 | 14:15 | 16:05 | 17:55 | 12:58 |
| 28.01.2015 | 05:35 | 06:15 | 07:45 | 12:00 | 14:17 | 16:08 | 17:56 | 12:58 |
| 29.01.2015 | 05:33 | 06:13 | 07:43 | 12:00 | 14:19 | 16:10 | 17:58 | 12:58 |
| 30.01.2015 | 05:32 | 06:11 | 07:41 | 12:00 | 14:21 | 16:12 | 18:00 | 12:58 |
| 31.01.2015 | 05:30 | 06:09 | 07:39 | 12:00 | 14:23 | 16:14 | 18:02 | 12:58 |

# "Хузур" нәшрият йорты тәкъдим итә

Нәшрият йорты бастырып чыгарган "Что такое ислам" дигән брошюрада исламның биш баганасы - шәһадәт, намаз, ураза, зәкят, хаҗ һәм аларны үтәү кагыйдәләре турында кыскача аңлатма бирелгән. Әлеге брошюра "Просто о важном" сериясеннән беренче карлыгач, алга таба чыгачак брошюраларда да нәшрият йорты ислам нигезләренә кагылышлы байтак мәсьәләләргә аңлатмалар бирергә җыена.




Намаз - исламның икенче өркене, баганасы. Намаз - мөселманның бу тормышта Аллаһы биргән барлык нигъмәтләр өчен Аңа илтифатын, хөрмәтен күрсәткән гамәле. Намаз - Раббыбыз белән элемтә булдыручы бер чылбыр кебек. Коръәни-Кәримдә: "Әй, иман китергәннәр, намаз укыгыз һәм садака бирегез",- дип Аллаһы тәгалә иман китергән кешеләргә мөрәҗәгать итә. "Хузур" нәшрият йортында дөнья күргән "Тәһарәт һәм намаз" китабы менә шушы олуг гыйбадәтне башкаруның әһәмиятен, тәртибен аңлата. Шулай ук китапта намаз гыйбадәтенең бер шарты булган тәһарәткә дә олы әһәмият бирелә. "Тәһарәт һәм намаз" китабы имамнарга, мөәзиннәргә, мәчет каршындагы башлангыч мәдрәсә мөгаллимнәренә һәм шулай ук киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.




***"Хузур" нәшрият йорты нәшер иткән "Тәһарәт һәм намаз" китабы "Зур Казан" типографиясендә басылган.***




Нәшрият йорты үз укучыларын тагын бер яңа басма - мәшһүр татар ислам дине тәгълиматчысы Ризаэддин Фәхреддиннең "Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм" китабы белән сөендерде. Әлеге басмада Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тормышында булган әһәмиятле вакыйгалар, аның хатыннары һәм балалары турында бәян ителгән.

Китап киң катлам укучыларга, шулай ук татар тәгълиматчылары мирасы белән кызыксынучыларга адреслана.

"Мөхәммәд" китабы 1909 елда Оренбургта нәшер ителгән. Автор бу китапны нәшрият ачылу уңаеннан 1908 елда "Вакыт" нәшрияты хуҗалары Рәмиевләргә бүләк итә. Шулай итеп, китап нәшрият бастырган беренче басма булып тора. Китапның кереш өлешендә автор үз хезмәтен көндәлек тормышта куллану өчен кирәкле тарихи очерк дип атый. Һәр мөселманның Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм биографиясен һәм өйрәтүләрен белергә тиешлеге турында әйтә.

Иске татар имлясындагы әсәрнең татарчага күчермәсен һәр рус теленә тәрҗемәсен ТР МДНнең укуукыту бүлеге җитәкчесе Айдар Карибуллин әзерләде.

## Теләчедәге ятим инвалид балалар йортына ярдәм кирәк

**Теләчедәге ятим инвалид балалар йортына ярдәм кирәк. Искәртеп үтәбез, 22 ноябрьдән ятимнәр йортына балалар урнаша башлады. Биредә тәрбияләнүче сабыйлар әти-әниләре тарафыннан ташланган. Араларында сукырлар, даун һәм ДЦП диагнозы куелган балалар бар.**

**Бүгенге көндә аларга шәхси гигиена әйберләре кирәк. Финанс ярдәме күрсәтергә теләгән һәр кеше** *7715 номерына "Нур" сүзе белән СМС-хәбәр җибәрә ала*.

**Барлык кирәк-яракларны Казанның Ярдәм мәчетенә дә китерергә мөмкин.**

## ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕНДӘ ТАТАР ТЕЛЕ КУРСЫ БАРА

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең татар җәмәгатьчелеге белән эшләү бүлеге "Зәкят" фонды белән берлектә нәзарәт бинасында (3 нче катта) һәр атнаның җомга көннәрендә 16.00 сәгатьтә татар теленә өйрәтү курсын уздыра. Казан шәһәренең мәчетләрендә эшләүче хезмәткәрләрне һәм шулай ук татар телен өйрәнергә теләгән барлык кардәшләрне дә көтеп калабыз. Дәресләрне Идел буе Федераль университетының татар филологиясе институты укытучысы Фирүзә Рәмзил кызы алып бара, уку тәмамлангач сертификат бирү каралган. Теләге булган кешеләргә намаз укырга өйрәнү мөмкинчелеге дә бар.

**Курсларга язылу өчен 8 (927) 413-82-44 телефонына шалтыратырга кирәк. Сезне көтеп калабыз! Рәхим итегез!**

ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

*Декабрь саны, № 12(232)*

**Мөхәррир:** Нәүбәһар Кәбирова
**Дизайнер:** Гүзәл Миңнуллина
**Корректор:** Айгөл Крохина
Газета логотибы **хәттат** Рамил Насыйбуллов тарафыннан эшләнде

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:** *420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27/*
**Электрон адрес:** *naubahar67@list.ru.*
**Телефон:** *+7 (843) 267-29-67*

**Редакция советы:**
*Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе* ***Камил СӘМИГУЛЛИН****;*
*"Хузур" нәшрият йорты директоры* ***Ришат ХӘМИДУЛЛИН****;*
*ТҖМДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе* ***Нияз САБИРОВ****;*
*Татарстанның баш казые* ***Җәлил ФАЗЛЫЕВ****;*
*Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы рәисе* ***Габдулла ӘДҺӘМОВ****.*

**Язылу индексы: 16046**
**Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин**

**Гамәлгә куючы:** *Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27).*
**Нәшир:** *"Хузур" нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 10в)*

*Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.*
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета **"Татмедиа" ААҖ филиалы - "Идел-Пресс"** полиграфия-нәшрият комплексында басылды *(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2).*
**Тираж: 5 мең данә** Заказ **№ 09618**
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - **6 сум.**
График буенча бу санга **26 нчы декабрь** көнне **18.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде.
Кул куелды: **18.00 сәгатьтә.**